ТАТССР

5 – 11 июль 2019 / № 26 (282)

# АТНА ВАКЫЙГАЛАРЫ

ГАЗЕТАНЫҢ ЭЛЕКТРОН ВЕРСИЯСЕ INTERTAT.TATAR САЙТЫНДА



Фотолар – tatarstan.ru

# Татарстанда кыр көне

**Республикада ел саен үткәрелә торган кыр көне – Идел буе төбәгендә авыл хуҗалыгы продукциясен, товарларын һәм хезмәтләрен тәкъдим итә торган зур күргәзмә ул.**

Булат ФӘТТАХОВ

Кыр көнендә яхшы уңыш алу өчен орлыклар, ашламалар, үсемлекләрне саклау чаралары, үсемлекчелектә һәм терлекчелектә кулланыла торган технологияләр, техниканы барлыйлар. Лаеш районының Олы Кабан авылы янындагы кырда үткәрелгән быелгы күргәзмәдә Россиянең 24 төбәгеннән 167 компания катнашты.

Күргәзмә белән Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, РФ авыл хуҗалыгы министры урынбасары Иван Лебедев, ТР Премьер-министры урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык төлек министры Марат Әхмәтов танышты. Рөстәм Миңнеханов Россия Дәүләт селекция казанышларын сынау һәм саклау комиссиясенең Татарстан филиалына яңа 5 комбайн алу өчен сертификатлар тапшырды.

– Авыл хуҗалыгында яңа технологияләр кулланмасаң, көндәшлекне саклау мөмкин түгел. Быелгы күргәзмәдә автопилот системасы белән тәэмин ителгән трактор, терлекчелек өлкәсендә иң заманча технологияләр, корылыкка чыдам авыл хуҗалыгы культуралары тәкъдим ителде. Авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәренә үзара бәйләнешләрне ныгыту өчен яхшы мөмкинлек булды, – диде **Рөстәм Миңнеханов**.

> Күргәзмә кысаларында оештырылган мастер-класслар, «түгәрәк өстәл»ләр, конференцияләр 3,5 меңнән артык белгечне җәлеп итте.

Президент заманча проектларны Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгы ярдәменнән башка тормышка ашыру кыенга туры килер иде дип, бүген зур предприятиеләргә дә, кечкенәләренә дә федераль дәрәҗәдә ярдәм күрсәтелүен искәртте.

РФ авыл хуҗалыгы министры урынбасары **Иван Лебедев** Татарстан Хөкүмәтенең авыл хуҗалыгын үстерүгә зур игътибар бирүен әйтте. «Мондый уңышлы төбәкләр күбрәк булса, илебезнең авыл хуҗалыгы тармагы тизрәк үсәр иде», – диде ул.



## ТАТАРСТАН АРПА ҮСТЕРӘЧӘК

Кыр көнендә республика җитәкчелеге катнашында Татарстан Республикасы белән Европаның «АБ ИнБев Эфес» сыра кайнату компаниясе арасында хезмәттәшлек турында килешү төзелде. Әлеге килешү нәтиҗәсендә 2023 елда Татарстанда арпа үстерү һәм сату күләме 40 тапкырга артыр дип көтелә. Бу проект авыл хуҗалыгына яңа инвестицияләр, эш урыннары, технологияләр алып киләчәк, яңа сортлар уйлап табуга этәргеч бирәчәк. Мәсәлән, Европа компаниясе арпаның күпме уңыш бирүен анализларга ярдәм итә торган технология белән бүлешергә әзер. Ул арпа үстерү буенча дөнья күләмендәге тәҗрибә белән уртаклашып, ел саен курслар оештырырга тели.

Рөстәм Миңнеханов әлеге компания белән күпьеллык хезмәттәшлекнең дәвам итүенә куанучын белдерде. Бу проект авыл хуҗалыгын үстерергә һәм табышны арттырырга мөмкинлек бирәчәк, диде ул. Әйтергә кирәк, Европа компаниясе ел саен Россия фермерларыннан 3 миллиард сумлык арпа сатып ала, 10 төбәк белән хезмәттәшлек итә.

## ФЕРМЕРЛАР ГРАНТЛЫ БУЛДЫ

Кыр көнендә федераль программа буенча чираттагы грантларны откан гаилә терлекчелек фермаларына, үз эшен башлаучы фермерларга һәм авыл хуҗалыгы кооперативларына сертификатлар тапшырылды.

Грант алучылар арасында терлекчелек, атчылык, кошчылык юнәлешендә, шулай ук җиләк-җимеш, бәрәңге, яшелчә, бөртекле-кузаклы һәм терлек азыгы культуралары үстерүчеләр бар иде.

## ИҢ ОСТА СЫЕР САВУЧЫ – МАМАДЫШТАН

Республикада сыер савучылар арасында 46нчы тапкыр оештырылган осталык бәйгесенә нәтиҗәне дә Кыр көнендә ясадылар. Ярышта һәр районда иң яхшы күрсәткечләргә ирешкән операторлар көч сынашты. Алар теориядән дә, практикадан да имтихан тотты. Терлекләрне ашату, асрау, сөт саву аппаратыннан файдалану, сыйфатлы сөт алу, куркынычсызлык техникасы буенча белемнәрен күрсәтте.

Бу көнне сыер савучылар берсеннән-берсе матур иде. Кыр уртасында узган чарада Казанның Халыкара сервис көллияте студентлары сыер савучылар өчен гүзәллек салоны хезмәтен тәкъдим итте. Ханымнар һәм туташлар чәчтарашханә, бизәндерүче, маникюр хезмәтләреннән файдаланды.

Мамадыш районының «Продпрограмма» аграр сәнәгать компаниясеннән Сания Насыйбуллина машина белән саву буенча 2019 елда Татарстанның абсолют чемпионы булып танылды.

Актаныш районының «Башак» ҖЧҖ хуҗалыгыннан Гүзәл Әхмәтова линия җәйланмасында сыерларны машина белән саву буенча чемпион исеменә лаек булды. Азнакай районының «Азнакай» агрофирмасыннан Резеда Газыева – икенче, Биектау районының «Татарстан» агрофирмасыннан Рузалия Идрисова өченче урынны алды.

Биектау районының «Татарстан» хуҗалыгыннан Фирдия Галәветдинова сөт саву залында сыерны машина белән савучы иң яхшы оператор дип табылды. Аның терлекчелек тармагында эш стажы инде 40 елга тула. Бәйгенең иң яшь катнашучылары да игътибарсыз калмады – Чистай районының «Закрома» ҖЧҖ хуҗалыгыннан Алена Курбатова бүләкләнде. Үткән ел нәтиҗәләре буенча аеруча югары нәтиҗәләргә ирешкән өчен Кукмара районының «Рассвет» агрофирмасында сыер савучы Ирина Трофимовага хөрмәт күрсәтелде.

Биектау районыннан Рөстәм Сабиров терлекчелек буенча иң яхшы киңәшче буларак билгеләп үтелде. Шулай ук 4 һәм аннан күбрәк бала тәрбияләүче сыер савучылар, иң озын толымлы, нечкә билле, алтын чәчле, гаиләләре белән терлекчелек тармагында хезмәт куючы ханымнар да бүләксез калмады.

Бу хакта тулырак
ТИ TATAR-INFORM.TATAR
сайтында
16+

## Кыскача

Бу атнада Казанда **РОССИЯ АНТРОПОЛОГЛАРЫ ҺӘМ ЭТНОЛОГЛАРЫНЫҢ XIII КОНГРЕССЫ** узды. Анда Россиянең төрле төбәкләре һәм 20 илдән милләтләрне һәм милләтара мөнәсәбәтләрне өйрәнүче галимнәр җыелды. Россия Фәннәр академиясенең Н.Н.Миклухо-Маклай исемендәге Этнология һәм антропология институты җитәкчесе Валерий Тишков этнологларның ике елга бер оештырыла торган җыенын Казанда үткәрергә тәкъдим иткән иде. Конгресста Татарстан Фәннәр академиясе, Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты, А.Халиков исемендәге Археология институты галимнәре, милли-мәдәни оешма вәкилләре катнашты. Бүген Татарстан халыклары Ассамблеясына 37 милләтнең 230 төбәк һәм җирле иҗтимагый берләшмәсе керә. Конгресста Россиядә милләтләр һәм диннәр арасындагы мөнәсәбәтләр, 2025 елга кадәрге дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру барышы турында фикер алыштылар.

30 июньдә Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, артист, **АМАНУЛЛА ТӘХӘЛЛҮСЕ БЕЛӘН ИҖАТ ИТКӘН ДРАМАТУРГ ӘМИР КАМАЛИЕВ ВАФАТ БУЛДЫ.** Быел 29 майда аңа 59 яшь тулган иде. Артист белән хушлашу чарасы Г.Кариев исемендәге Татар дәүләт яшь тамашачы театрында узды. Әмир Камалиев туган ягында – Апас районы Шыгай авылында җирләнде.

3-7 июльдә республикада егерме дүртенче тапкыр **«АЛТЫН КАЛӘМ» РЕСПУБЛИКА БАЛАЛАР, ЯШҮСМЕРЛӘР ҺӘМ ЯШЬЛӘР МАТБУГАТЫ ФЕСТИВАЛЕ УЗА.** Анда журналист булырга теләгән яшьләр арасында басма матбугат, телевидение, радио, мультимедиа, дизайн һәм верстка юнәлешләрендә бәйгеләр оештырыла. Аларда көн кадагындагы темалар күтәреләчәк – Татарстанда Эшче һөнәрләр елы, Россиядә Театр елы, ТАССРның 100 еллыгы, Татарстанда дәүләт яшьләр сәясәтенең 25 еллыгы һ.б. Быел фестивальдә 24 районнан 120 кыз һәм малай катнаша. Җиңүче КФУның журналистика бүлегенә юллама белән бүләкләнәчәк. «Алтын каләм» фестивалендә журналистлар бергәлеге барлыкка килә, анда катнашучылар гомер буе аңа тугры булып яши. Алар журналист һөнәрен сайласа да, башка юнәлештән китсә дә иҗат рухын саклый», – диде фестивальнең жюри рәистәше Римма Ратникова.

Бу атнада ТР Дәүләт Советының Шакир Яһудин рәислегендәге **ЗАКОНЛЫЛЫК ҺӘМ ХОКУК ТӘРТИБЕ КОМИТЕТЫ 2014-2019 ЕЛЛАРДАГЫ ЭШЧӘНЛЕГЕНӘ НӘТИҖӘ ЯСАДЫ.** Депутатлар, шул исәптән «Бердәм Россия» фракциясе әгъзалары үткән биш елда законнарны камилләштерүдә катнашты. Алар «Татарстанда җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында»гы ТР законын әзерләде. «Парламент контроле» төшенчәсенә законлы статус биреп, «Татарстанда парламент контроле турында»гы ТР законы кабул ителде. Шулай ук берничә закон проектын федераль парламентка тәкъдим иттеләр.

Казанның **«УНИВЕРСИАДА АВЫЛЫ» ЭШЧЕ ҺӨНӘРЛӘР БУЕНЧА 45НЧЕ WORLDSKILLS (ВОРЛДСКИЛЛС) ДӨНЬЯ ЧЕМПИОНАТЫ КУНАКЛАРЫН КАРШЫ АЛЫРГА ӘЗЕРЛӘНӘ.** Бу территориядәге тулай торакларга 5,5 мең кеше урнаштырылачак. Чемпионатта катнашучылар, техник хезмәткәрләр һәм волонтерлар да биредә яшәячәк. Бүгенге көндә 53 гектарны биләгән территориядә 28 тулай торакның барысында да ремонт эшләре бара. Монда кибет, кафе, почта, ателье, кер юу һәм химик чистарту хезмәтләре дә булачак. Чемпионат барган көннәрдә чит телләрне яхшы белгән 300 кешене вакытлыча эшкә алачаклар.

БИК ТӘ МӨҺИМ ҺӘМ
КЫЗЫКЛЫ ХӘЛНЕҢ
ШАҺИТЫ БУЛДЫГЫЗМЫ?
Редакциягә хәбәр итегез!
+7 927 037–91–10
info@tatar–inform.tatar
WhatsApp Telegram
АША ЯЗАРГА МӨМКИН

# ЭШМӘКӘРЛӘРГӘ – тигез шартлар

**Татарстанда үз продукциясен сатарга теләгән зур предприятиеләргә дә, кече эшмәкәрлек вәкилләренә дә дәүләт тигез шартлар тудырды.**




Фото – tatar-inform.ru архивыннан

Гөлназ ГЫЙЛФАНОВА

Татарстанда җитештерүчеләрнең продукциясен таныту өчен яңа электрон система эшли башлады. Ул эшмәкәрләргә тиз арада үз продукциясенә сатып алучылар табарга, ә сатып алучыларга кирәкле продукция эзләп вакыт сарыф итмәскә, ведомстволарга исә икътисади үсеш мөмкинлекләрен барларга ярдәм итә. Татарстан икътисад министры **Фәрит Габделганиев**, яңа система белән таныштырып, шул хакта сөйләде. Министр сүзләренчә, бу система май аенда эшли башлаган һәм үзенең нәтиҗәлелеген күрсәткән, кече һәм урта эшмәкәрләргә аның ярдәме тигән.

– ТР Президенты март аенда Татарстан продукциясен таныта торган электрон система булдыру турында Указ чыгарган иде. Бу системаның максаты – эшмәкәрләргә нинди продукциягә ихтыяҗ барлыгын күрсәтү. Эшмәкәрлек үсеш кичергән саен, яңа эш урыннары һәм базарда көндәшлек барлыкка килә, соңгысы бәяләргә тәэсир итә, – диде министр.

Ул районнарда кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү бурычы торганын әйтте. Икътисад министрлыгы белгечләре, атна саен районнарга чыгып, эшмәкәрләрне яңа электрон сату хезмәтеннән файдаланырга өйрәтә. Якын арада министрлык Татарстанга кайсы төбәкләрдән нинди товарларны күбрәк алып керүләрен ачыкларга ниятли. Шул рәвешле, аларны республикада җитештерү мөмкинлеге каралачак. Һәр районны билгеле бер продукция белән тәэмин итүче итеп билгеләү күздә тотыла.

Татарстан Дәүләт заказлары агентлыгы башлыгы **Яков Геллер** журналистларга хәбәр иткәнчә, ай ярым эчендә рес-публиканың Чүпрәле, Аксубай, Әлмәт, Алексеевск, Саба һ.б. районнарындагы 56 предприятие яңа электрон сату системасыннан файдаланган. Системаның каталогында исә хәзер йөзләгән товар һәм хезмәт тәкъдим ителгән, аларның саны көн саен арта.

Электрон сәүдә системасы **zakazrf.ru** интернет адресы буенча урнашкан Федераль электрон сәүдә мәйданчыгы базасындагы «Биржа мәйданчыгы»нда (**bp.zakazrf.ru**) оештырылган.

– Без әле зур юлның башында гына торабыз. Шулай да инде 23 район бу эшкә кушылды, аларда җаваплы кешеләр билгеләнде. Җитештерүчеләрдән 600дән артык тәкъдим керде – ай ярым вакыт өчен бу бик яхшы күрсәткеч, – диде Яков Геллер.

Аның сүзләренчә, әлеге системадан үзмәшгульләр дә файдалана ала.

– Бу – яңа икътисади шартлар, без базарда катнашучыларның бөтенесе өчен дә тигез шартлар тудырабыз. Электрон системада зур предприятие һәм гади эшмәкәр арасында аерма юк – ул барысы өчен дә ачык, – диде агентлык җитәкчесе.

Быел Санкт-Петербургта узган Халыкара икътисади форумда Татарстанның үз җитештерүчеләрен таныту тәҗрибәсе югары бәя алып, кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итүдә нәтиҗәле чара буларак, Россиянең башка төбәкләрендә дә файдаланырга тәкъдим ителде.

# Илгиз Мәҗитовның истәлеге мәңгеләштерелде

Бу атнада Казанда күренекле композитор, җырчы, Россиянең һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Илгиз Мәҗитовка (1932-2004) мемориаль такта ачылды. Ул композитор озак еллар яшәгән Кече Кызыл урамындагы 14нче йорт диварына урнаштырылды. Тантаналы чарада ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе директоры Кадыйм Нуруллин, сәхнә ветераннары, артистлар катнашты.

Илгиз Мәҗитов тумышы белән – Казаннан. 1960 елда консерваторияне тәмамлап, Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенә солист-вокалчы булып эшкә килә. 1967 елда Мәскәүнең Театр сәнгате институтына укырга керә. 1973 елда Татар дәүләт опера һәм балет театрына баш режиссер, 1976 елда филармониянең сәнгать җитәкчесе итеп билгеләнә. Аның композитор буларак иҗаты аерым урын алып тора. «Ак каеннар шаулый болында», «Урман юлында», «Яшьлегем сукмаклары», «Кайтырмын» һәм башка җырларын профессиональ артистлар да, һәвәскәрләр дә үз репертуарына кертә.

– Бөтен гомерен татар сәнгатенә багышлаган Илгиз Мәҗитовнең истәлеге кадерләп сакланырга тиеш, – диде Минтимер Шәймиев.




Р.Гали фотосы

# Рөстәм Миңнеханов: «Илкүләм проектлар, һичшиксез, гамәлгә ашырылачак»



Фото – tatarstan.ru

**Идел буе федераль округы төбәкләре вәкаләтле органнары вәкилләре Татарстанның икътисад өлкәсендәге инновацион эшчәнлеге һәм цифрлы технологияләрне гамәлгә кертү тәҗрибәсе белән танышты.**

Булат ФӘТТАХОВ

Россиянең Идел буе федераль округы төбәкләрендәге дәүләт хакимияте закон чыгару органнары ассоциациясе вәкилләре Татарстанга җыелды. Иннополис шәһәрендә оештырылган очрашуның максаты – быелдан Россиядә төрле юнәлешләрдә гамәлгә ашырыла башлаган илкүләм проектларның үтәлешен тәэмин итү өчен фикер алышудан гыйбарәт иде. Бер уңайдан Идел буе төбәкләре парламентарийлары Татарстанның инновацион эшчәнлеге һәм барлык тармакларга да цифрлы технологияләрне кертү тәҗрибәсе белән таныштылар. Чөнки илкүләм проектлар арасында «Цифрлы икътисад» юнәлешенә багышланганы да бар. Иннополис – әлеге тармакны кадрлар белән тәэмин итәргә тиешле урын.

Идел буе федераль округы төбәкләре закон чыгару органнары ассоциациясенең 56нчы утырышында Россия Президентының Идел буе федераль округындагы вәкаләтле вәкиле Игорь Комаров, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Идел буендагы 14 төбәк вәкилләре дә катнашты.

**Игорь Комаров** хакимият органнарына илкүләм проектларны гамәлгә ашырганда Россия Президенты куйган бурычларны, җәмәгатьчелек, төбәкләрдә яшәгән кешеләр җиткергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, эзлекле һәм актив эшчәнлек алып барырга, тәҗрибә уртаклашып торырга кирәклеген искәртте.

**Рөстәм Миңнеханов** илкүләм проектларны тормышка ашырганда законнарны камилләштерү мөһим роль уйнавына басым ясады. Ул да мондый очрашулар төбәкләрнең уңай тәҗрибәләрен белергә ярдәм итәчәгенә өметен белдерде. «Бүген бөтен юнәлешләр буенча да җитди эш бара. Илкүләм проектлар, һичшиксез, гамәлгә ашырылачак», – диде ул.

### ЗАКОННАРНЫ КАМИЛЛӘШТЕРҮ ТУРЫНДА

**Фәрит Мөхәммәтшин** Татарстан мисалында Идел буе федераль округы субъектларында инновацион эшчәнлек һәм цифрлы технологияләрне гамәлгә кертү тәҗрибәсе белән таныштырды. Ул республикада бу юнәлештә, беренче чиратта, махсус законнар һәм норматив хокукый актлар кабул ителүе турында сөйләде. Мәсәлән, 2010 елда кабул ителгән «Татарстан Республикасында инновацион эшчәнлек турында»гы законны, шулай ук 2015 елда закон статусын алган Татарстанның 2030 елга кадәрге социаль-икътисади үсеш стратегиясен телгә алырга мөмкин.

Фәрит Мөхәммәтшин сүзләренчә, республикада инновацион продуктларны төп файдаланучылар – нефть табу, нефть химиясе, энергетика, машина, авиация һәм суднолар төзү тармаклары, оборона-сәнәгать комплексы, авыл хуҗалыгы. Яңадан-яңа инновацион продуктлар булдыруда республиканың фәнни оешмалары да өлеш кертә.

Татарстан парламенты башлыгы «ИнноКам» Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерын уңай мисал буларак телгә алды. Биредә импортны алмаштыра торган 79 инвестицион проект гамәлгә ашырыла, кешеләргә яңа эш урыннары булдырыла. «Алабуга» махсус икътисади зонасы да шушы «ИнноКам» кластерының бер өлеше булып тора. Болардан тыш, технопарклар арасында «Химград» технополисы эшчәнлеге игътибарга лаек: анда полимерлар, нано– һәм медицина технологияләре, ресурсларны саклау һәм энергия куллануның нәтиҗәлелеген арттыру проектлары белән шөгыльләнә торган 290 компания эшли. «Идея» инновацион-җитештерү технопаркы исә бизнес-инкубаторлар аша яшь инновацион компанияләрне үстерергә ярдәм итә. Югары технологияләр өлкәсендәге проектлар белән шөгыльләнә торган «АйТи-парк» технопаркында компьютер технологияләре өчен программа тәэминатлары эшләнә.

Фәрит Мөхәммәтшин технопарк, технополислардагы проектларны предприятиеләрдә кулланышка кертүдә төбәк инжиниринг үзәкләре ярдәм итүен әйтте. «Без дөньяның алдынгы казанышларын күзәтеп барабыз, тәҗрибә уртаклашырга тырышабыз. Бу юнәлештә республика Президенты актив эшли», – диде Фәрит Мөхәммәтшин. Әйтергә кирәк, 2010 елда Татарстан Россиянең инновацион төбәкләре ассоциациясен гамәлгә куюда катнашты. Бу оешманы Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов җитәкли.

Фәрит Мөхәммәтшин төбәк дәрәҗәсендә инновацияләрне үстерү белән шөгыльләнгәндә килеп туган кыенлыкларны җиңәр өчен еш кына законнарны үзгәртергә, камилләштерергә туры килүен искәртте. Мәсәлән, Татарстан Дәүләт Советы быел июнь аенда Россиядә Салым кодексына үзгәрешләр кертү турындагы федераль закон проектын карады һәм хуплады. Анда махсус икътисади зоналардагы резидентларга, яңа техник һәм технологик продуктларны һәм хезмәтләрне кулланышка керткән өчен, салым ташламалары бирергә тәкъдим ителә. «Без бу закон проекты белән Россия Дәүләт Думасына мөрәҗәгать итеп, аны тиз арада карарга һәм кабул итәргә тәкъдим итәбез», – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Утырышта Ассоциациянең координаторы итеп яңадан Пенза өлкәсе парламенты Рәисе **Валерий Лидин** сайланды. Ул әлеге Ассоциациянең тәкъдимнәре федераль дәрәҗәдә һәрвакыт хуплануын әйтте. «Татарстан – икътисад һәм социаль өлкәләрдә алга киткән төбәкләрнең берсе. Инновацион технологияләрне, цифрлы икътисадны үстерүдә дә аның тәҗрибәсен Идел буендагы башка төбәкләргә таратырга кирәк», – диде ул.

### «Цифрлы икътисад» илкүләм проекты

- Гамәлгә ашыру вакыты – 2024 елга кадәр
- 5 ел эчендә Россия икътисады һәм социаль өлкәсе комплекслы цифрлы үзгәрешләр кичерәчәк




**Түбәндәгеләр булдырылачак:**

1. Мәгълүматларны эшкәртү һәм саклауда көндәшлеккә сәләтле инфраструктура
2. Цифрлы технологияләр өлкәсендәге тикшеренүләргә ярдәм итү системасы
3. Кадрлар әзерләүдә камилләштерелгән система *(гражданнарны цифрлы технологияләрне кулланырга өйрәтү, математика һәм информатика өлкәсендә талантлы мәктәп укучыларына, студентларга, мөгаллимнәргә ярдәм итү)*



- Татарстанда 2021 елга 3 меңгә якын социаль әһәмияткә ия объект (ФАП, мәктәп, янгын сүндерү частьләре) югары тизлекле интернет белән тәэмин ителәчәк
- 2024 елга халык белән дәүләт органнары арасындагы үзара элемтә тулысынча электрон форматка күчәчәк



- 2024 елга республика предприятиеләре цифрлы технологияләрне үстерү өчен дәүләт ярдәме алачак

## «ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР» – ИҖТИМАГЫЙ КӨЧ

**«Татарстан – Яңа гасыр» республика иҗтимагый хәрәкәте оешуга 20 ел тулды.**

Ләйсән ВӘЛИЕВА

Бу вакыйга уңаеннан Спас районының Болгар шәһәрендә «Кеше – интернет киңлегендә» дигән фәнни-гамәли конференция узды. Татарстан Президенты, иҗтимагый хәрәкәтнең юбилее белән котлап, конференциядә катнашучыларга язмача мөрәҗәгать юллады. Аны ТР Президенты Аппараты җитәкчесе урынбасары – Эчке сәясәт мәсьәләләре буенча департамент башлыгы, «Татарстан – Яңа гасыр» иҗтимагый хәрәкәте Югары советы әгъзасы **Александр Терентьев** укыды. «Әлеге иҗтимагый хәрәкәт тарихи һәм мәдәни мираска, демократия һәм федерализм принципларына таянып, республиканың үсеше өчен көч куйган кешеләрне берләштерә», – дип, ТР Президенты «Татарстан – Яңа гасыр» хәрәкәтенә уңай бәя биргән, уңышлар теләгән.

Иҗтимагый хәрәкәт вәкилләрен ТР Дәүләт Советы Рәисе **Фәрит Мөхәммәтшин** дә тәбрикләде. Ул бүген «Татарстан – Яңа гасыр» хәрәкәте 12 иҗтимагый оешманы, алар, үз чиратында, 100 мең кешене берләштерүен әйтте. 20 ел элек хәрәкәт башында торган Марат Галиев, Рифат Ганибаев, Илдус Мостюков, Рафаил Хәкимов кебек шәхесләрне искә алды. Хәзерге көндә аның Башкарма комитеты белән Алсу Тарханова җитәкчелек итә.

– «Татарстан – Яңа гасыр» хәрәкәте активистлары сайлау кампанияләрендә даими катнашып килә. Алар арасында «Бөтен Россия» («Вся Россия»), «Ватан» («Отечество»), «Бердәм Россия» кебек партия һәм хәрәкәтләрнең Татарстандагы төбәк бүлекләрен төзүчеләр бар. Быел көзен Татарстан Дәүләт Советына депутатлар сайлауда «Бердәм Россия» партиясеннән кандидатларны билгеләү өчен май аенда үткәрелгән алдан тавыш бирүдә дә актив катнаштылар. Без максатыбызга ирештек – бу хәрәкәт республиканың социаль-икътисади һәм рухи үсешен, тотрыклылыгын тәэмин итәргә булыша торган иҗтимагый көчкә әверелде. Төбәкләр көчле булганда гына илебез көчле булачак, – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Ул кешеләрне борчыган көнүзәк проблемаларны белеп тору һәм хәл итү өчен республика район-шәһәрләрендә әлеге хәрәкәтнең иҗтимагый кабул итү пунктлары санын арттырырга һәм хәрәкәт эшенә яшьләрне күбрәк тартырга киңәш итте.

Фәрит Мөхәммәтшин интернетның җәмгыять белән хакимият арасын якынайту өчен уңайлы шартлар тудыруын искәртте. Интернет киңлеген саклау мәсьәләсе актуальләшә баруын, шул сәбәпле яңа федераль законнар кабул ителүен билгеләп үтте, интернет технологияләрне үстерүче кадрлар әзерләү мәсьәләсенең әһәмиятенә тукталды.

# Бакчачылар да бәйрәм итәчәк

Татарстан Дәүләт Советы депутатлары бакчачыларга җир асты суларыннан файдаланырга рөхсәт итә торган лицензия алу вакытын озайтырга һәм Бакчачылар көнен булдырырга тәкъдим итә.



Фото – «Әгерже хәбәрләре» архивыннан

Булат ФӘТТАХОВ

Татарстан парламентының Экология, табигатьтән файдалану, аграр сәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитетында бакчачылыкка һәм авылларга дәүләт ярдәме күрсәтү мәсьәләләренә багышланган утырыш булды. Анда республиканың дәүләт хакимияте органнары, коммерцияле булмаган бакчачылык берләшмәләре, авыл хуҗалыгы уку йортлары вәкилләре чакырылган иде.

### ҺӘР ӨЧЕНЧЕ ГАИЛӘНЕҢ БАКЧАСЫ БАР

ТР Дәүләт Советы депутаты, Дәүләт төзелеше һәм җирле үзидарә комитеты әгъзасы, «Бердәм Россия» партиясенең «Бакчачы йорты – гаилә терәге» проекты координаторы **Валерий Власов** Татарстанда Бакчачы көнен булдырырга тәкъдим итте. Аның сүзләренчә, республикада меңнән артык коммерцияле булмаган бакчачылык һәм яшелчәчелек берләшмәсе бар. Миллионга якын кеше бакчачылык белән шөгыльләнә. Моннан тыш, 540 меңгә якын шәхси ярдәмче хуҗалык исәпләнә, ягъни үз йортлары белән яшәүчеләрнең күпчелеге бакча тота, яшелчә үстерә.

Валерий Власов искәрткәнчә, Татарстанда бакчачыларга ярдәм итәргә тырышалар. 2017 елдан республика бюджетыннан коммерцияле булмаган бакчачылык һәм яшелчәчелек берләшмәләренең инфраструктурасын үстерү буенча махсус программа финанслана. Аның кысаларында ел саен коммерцияле булмаган бакчачылык ширкәтләренең тышкы инфраструктура объектларын ремонтлауга 550 миллион сум акча бүленә. Ә 2018 елдан тагын бер программа гамәлгә керде: әлеге ремонт эшләренә тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау өчен бюджеттан субсидияләр бирелә.

Валерий Власов шулай ук «Бакчачы көне» бәйрәмен булдырырга һәм аны ел саен сентябрьнең беренче шимбәсендә билгеләп үтәргә тәкъдим итте.

Мондый бәйрәмне Россиянең кайбер төбәкләрендә үткәрәләр. Комитет әгъзалары әлеге тәкъдимне якын арада парламент утырышына чыгарырга карар кылды.

### СУГА ЛИЦЕНЗИЯ АЛУ СРОГЫ ТУРЫНДА

Экология, табигатьтән файдалану, аграр сәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты җитәкчесе **Таһир Һадиев** Россия Дәүләт Думасы Рәисе Вячеслав Володинга Татарстан Дәүләт Советы исеменнән мөрәҗәгать әзерләнүе турында хәбәр итте. Анда сүз гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек белән шөгыльләнү яки дача хуҗалыгын тоту максатында оештырылган коммерцияле булмаган оешмаларында хуҗалык-көнкүреш өчен җир асты суларыннан лицензиясез файдалану вакытын озайту турында бара. Бүгенге закон буенча, җир асты суларын лицензиясез 2020 елның 1 гыйнварына кадәр генә файдаланырга ярый.

– Бакчачылык ширкәтләре җир асты суларыннан файдалануга лицензия алу юнәлешендә эшли. Әмма тиешле документларны җыю вакыт һәм чыгымнар таләп итә. Шуңа күрә депутатлар федераль парламентка лицензия алу вакытын озайту мөмкинлеген карарга киңәш итәчәк, – диде Таһир Һадиев.

# Мөрәҗәгатьнең зурысы-кечесе юк

Бу атнада «Бердәм Россия» партиясе рәисе Дмитрий Медведевның Татарстан Республикасындагы иҗтимагый кабул итү бүлмәсендә депутатлар гражданнар белән очрашты.

Айрат САБИРОВ

Казанда урнашкан кабул итү бүлмәсендә сишәмбе көнне РФ Дәүләт Думасы депутаты Марат Бариев һәм ТР Дәүләт Советы депутаты Леонид Якунин гражданнарның гозер-үтенечләрен тыңлады.

Һәр атнаның сишәмбесе – Татарстан хакимияте органнарында гражданнарны кабул итә торган көн. Шулай ук 1-7 июльдә Россия Дәүләт Думасы депутатларының төбәкләрдә кабул итү көннәре уза. Татарстаннан сайланган депутатлар Ирек Зиннуров, Борис Менделевич, Ольга Павлова һәм Айрат Фәррахов та гражданнар белән очраша.

### ДЕПУТАТЛАРГА ЫШАНАЛАР

РФ парламентында Физик культура, спорт, туризм һәм яшьләр эшләре комитеты, «Бердәм Россия» партиясе фракциясе әгъзасы **Марат Бариев** сүзләренчә, кабул итү бүлмәсенә төрле яшьтәге кешеләр мөрәҗәгать итә. Алар арасында яшьләр дә, пенсионерлар да бар.

– Кешеләр җәмгыятьне борчыган көнүзәк мәсьәләләрне күтәрә. Мәсәлән, узган ел пенсия реформасына кагылышлы сораулар күп булды. Шулай ук җир кишәрлекләрен рәсмиләштерү, дәвалану, квоталар алу кебек шәхси сораулар белән дә киләләр, – диде Марат Бариев.

Бу юлы мөрәҗәгать итүчеләр арасында Казаннан икенче төркем инвалид ханым да бар иде. Ул шифаханәгә ташламалы юллама алуда булышуны сорап килгән. Ел саен шифаханәгә бару хокукы булса да, өч ел инде бернигә ирешә алмавын әйтте. Бу ханымның элек тә партиянең кабул итү бүлмәсенә мөрәҗәгать иткәне булган, ул чакта аңа Сочига юллама тәкъдим иткәннәр. Хәзер янә ярдәм сорарга мәҗбүр. Марат Бариев бу вәзгыятьне тикшерергә, бер атна эчендә җавап бирергә вәгъдә итте.

Әлбәттә, бөтен сорауларга да тиз генә җавап табу мөмкин түгел. Бу суд карарлары, банк заемнары, өлешләп түләнә торган төзелешләргә бәйле очракларга кагыла. Иҗтимагый кабул итү бүлмәсенә килгән тагын бер ханым 2014 елда өлешле төзелештә катнашып алдануы турында сөйләде. 2017 елда ул алданган өлешче буларак теркәлгән, Арбитраж суды аны яклап карар чыгарган. Ләкин моңа карап кына бернәрсә дә үзгәрмәде, дип сөйләде ул. Марат Бариев Татарстан Президентының төзелешләрдә өлешләп катнашып алданучылар мәсьәләсен контрольдә тотуын әйтте. Ул әлеге объект буенча нинди карарлар кабул ителүен белешергә вәгъдә бирде.

– Мөрәҗәгатьләр күп булды, димәк, депутатларга ышаналар. Кешеләр үз проблемалары белән килә, ярдәм, яклау эзли. Без аларның ышанычын акларга тырышабыз, чөнки депутатлар янына килгәнче, кешеләр бөтен инстанцияләрне йөреп чыккан була инде, – диде Марат Бариев, чираттагы очрашуга нәтиҗә ясап.

Татарстан Дәүләт Советы депутаты Леонид Якунинга гражданнар мошенник риелторлардан зарланып мөрәҗәгать итте, ташламалы торак алу, медицина тикшеренүләре узарга ярдәм итү кебек үтенечләрен җиткерде.

«Бердәм Россия» лидеры Дмитрий Медведевның иҗтимагый кабул итү бүлмәләре республиканың барлык шәһәр һәм районнарында да эшли. 2014-2019 елларда анда төрле сораулар белән 125 мең кеше мөрәҗәгать иткән.

# Татарстан цифрлы телевидениегә күчә

**Республикада аналоглы телевидение быелның 14 октябрендә эшләүдән туктаячак.**

Россиядә аналоглы телевидениедән цифрлы телетапшыруларга күчү планы РФ Хөкүмәтенең телерадиотапшыруларны үстерү комиссиясе карары белән узган елның ноябрендә расланган иде. Татарстан Республикасы, калган 56 төбәк белән бергә, аналоглы сигналны сүндерүнең өченче этабына керәчәк, дип хәбәр итә «Россия телевизион һәм радиотапшырулар челтәре» федераль дәүләт предприятиесе матбугат хезмәте.

14 октябрьдә аналоглы телевидение эшләүдән туктагач, аларның ешлыгында цифрлы телевидениегә күчәргә кирәклеге турында хәбәр чыгачак һәм бу язу бер атна күренеп торачак. Телевизор цифрлы тапшыруларны кабул итмәсә, махсус приставка сатып алып тоташтырырга кирәк.

Цифрлы телевидениене кабул итә башлагач, егермегә якын федераль каналны карап булачак. Төбәк телеканаллары һәм федераль каналларның мультиплексына кертелмәгән телеканаллар әлегә аналогта эшләячәк.

## Җомга, 12 июль

### 1 КАНАЛ

**5.00, 9.25** «Доброе утро».
**9.00** Новости.
**9.55** «Модный приговор». (6+)
**10.55** «Жить здорово!» (16+)
**12.00, 15.00, 18.00** Новости с субтитрами.
**12.15, 17.00, 18.25** «Время покажет». (16+)
**15.15** «Давай поженимся!» (16+)
**16.00** «Мужское / Женское». (16+)
**18.50** На самом деле. (16+)
**19.50** «Поле чудес». (16+)
**21.00** Время.
**21.30** «Три аккорда». (16+)
**23.15** «Вечерний Ургант». (16+)
**0.10** д/ф «Валерий Розов. Человек, который умел летать». (16+)
**1.10** х/ф **«Рокки Бальбоа»**. (14+)
**3.00** «Про любовь». (16+)
**3.50** «Наедине со всеми». (16+)

### РОССИЯ 1

**5.00, 9.25** Утро России.
**6.05, 7.05, 8.05** Вести-Татарстан. Погода.
**6.35, 7.35, 8.35** Вести-Татарстан. Утро.
**9.00** Яналыклар. Татарстан.
**9.30** «Хэерле кон, Татарстан!»
**9.55** «О самом главном». Ток-шоу. (12+)
**11.00, 14.00, 17.00, 20.00** Вести.
**11.25, 14.25, 17.45, 20.45** Вести-Татарстан.
**11.45** «Судьба человека с Борисом Корчевниковым». (12+)
**12.50** «60 Минут». Ток-шоу. (12+)
**14.45** «Кто против?» Ток-шоу. (12+)
**18.00** «Андрей Малахов. Прямой эфир». Специальный выпуск. (16+)
**21.00** т/с **«Сиделка»**. (12+)
**23.45** Торжественная церемония открытия XXVIII Международного фестиваля «Славянский базар в Витебске».
**1.40** х/ф **«Дама пик»**. (16+)
**3.50** «Белая студия».

### ТНВ

**5.00** «Халкым минем...» (12+)
**5.25, 10.55** «Нәсыйхәт». (6+)
**5.50, 7.00, 18.30, 20.30** Татарстан хәбәрләре. (12+)
**6.00** «Манзара». (6+)
**8.00, 14.30, 19.30, 21.30** Новости Татарстана. (12+)
**8.10** «Здравствуйте!» (12+)
**9.00** Док. фильм. (12+)
**10.00, 17.00** т/с **«Козайым»**. (12+)
**11.30** «Татарлар». (12+)
**12.00** т/с **«Жизнь и приключения Мишки Япончика»**. (16+)
**13.00** «Башваткыч». (6+)
**14.00** «Актуальный ислам». (6+)
**14.15** «Если хочешь быть здоровым...» (12+)
**14.45** «Аулак өй». (6+)
**15.15** т/с **«Зеркало, зеркало»**. (12+)
**18.00** «Туган җир». (12+)
**19.00** д/ф «Тарихлы шәһәрләр буенча сәяхәт». (12+)
**20.00, 22.00** «Вызов 112». (16+)
**20.15** «Күчтәнәч». (0+)
**21.00** «Адәм белән һава». (6+)
**22.10** «Сәхнәдәш». (12+)
**23.10** х/ф **«Өч йөрәк» («Три сердца»**). (16+)
**1.00** т/с **«Сиңа кайтам...»** (12+)
**3.40** «Караоке бәйге». (6+)
**4.30** «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт. (0+)

### ТАТАРСТАН 24

**0.00, 1.00, 2.00, 3.00, 4.00, 5.00, 6.00, 7.00, 8.00, 9.00, 10.00, 11.00, 12.00, 13.00, 14.00, 15.00, 16.00, 17.00, 18.00, 19.00, 20.00, 21.00, 22.00, 23.00** Новости Татарстана-24. (16+)
**0.30, 1.30, 2.30, 3.30, 4.30, 5.30** Жилищно-коммунальные Советы. (16+)
**6.30, 7.30, 8.30, 10.30, 16.30, 21.30** Полезные новости. Новости экономики, Суть дела с Григорием Тинским, iNews, Мобильный репортер, Дела судебные. (16+)
**9.30, 12.30** Самобытные культуры. (16+)
**11.30, 14.30** Удивительный мир. (16+)
**13.30, 15.30, 19.30** Главные новости. (16+)
**17.30, 20.30, 23.30** Актуальный разговор. (16+)
**18.30, 22.30** Великие сражения: кровь и сталь. (16+)

### ТВЦ

**6.00** «Настроение».
**8.00** д/с Большое кино. (12+)
**8.35, 11.55** х/ф **«Каменное сердце»**. (12+)
**11.30, 14.30, 19.40** События.
**13.10, 15.05** т/с **«Мой лучший враг»**. (12+)
**14.55** Город новостей.
**17.40** х/ф **«Люблю тебя любую»**. (16+)
**20.05** х/ф **«Идеальное убийство»**. (16+)
**22.00** «В центре событий» с Анной Прохоровой.
**23.10** Он и Она. (16+)
**0.40** х/ф **«Беглецы»**. (12+)
**2.30** Петровка, 38. (16+)
**2.45** х/ф **«Суровые километры»**. (0+)

### НТВ

**5.15** т/с **«Адвокат»**. (16+)
**6.00** «Утро. Самое лучшее». (16+)
**8.05** т/с **«Мухтар. Новый след»**. (16+)
**10.00, 13.00, 16.00, 19.00** Сегодня.
**10.20** т/с **«Лесник»**. (16+)
**13.25** Обзор. Чрезвычайное происшествие.
**14.00, 16.25** т/с **«Ментовские войны»**. (16+)
**18.25, 19.40** т/с **«Высокие ставки. Реванш»**. (16+)
**23.15** х/ф **«Гайлер»**. (18+)
**1.25** «Мы и наука. Наука и мы». (12+)
**2.15** Квартирный вопрос. (0+)
**3.05** х/ф **«Поцелуй в голову»**. (14+)

### КУЛЬТУРА

**6.30, 7.00, 10.00, 15.00, 19.30, 23.00** Новости культуры.
**6.35** д/с «Пешком...»
**7.05** д/ф «Тамплиеры: жертвы проклятого короля?»
**8.00** «Легенды мирового кино».
**8.35** х/ф **«Голубые дороги»**.
**10.15** д/с «Елена Образцова. Самая знаменитая и почти незнакомая».
**11.00** т/с **«Сита и Рама»**.
**12.35** IV Международный конкурс молодых оперных режиссеров «Нано-опера» в театре «Геликон-опера».
**14.45** Цвет времени.
**15.10** Спектакль «Пиковая дама».
**17.40** «Линия жизни».
**18.40** Мастера исполнительского искусства. Скрипка. Рено Капюсон.
**19.45** «Искатели».
**20.40** д/ф «Монологи кинорежиссера».
**21.25** х/ф **«Дирижер»**.
**23.20** х/ф **«Повелитель мух»**.
**0.50** «Только классика». Антти Сарпила и его Swing Band.
**1.30** д/ф «Дикая природа островов Индонезии».
**2.25** м/ф **«Кот в сапогах». «Великолепный Гоша»**.

### ДОМАШНИЙ

**6.30** «6 кадров». (16+)
**6.40** «Удачная покупка». (16+)
**6.50** д/с «Из России с любовью». (16+)
**7.50** «По делам несовершеннолетних». (16+)
**8.50** «Давай разведемся!» (16+)
**9.50, 5.10** «Тест на отцовство». (16+)
**10.50** т/с **«Брак по завещанию. Возвращение Сандры»**. (16+)
**19.00** т/с **«Прошу поверить мне на слово»**. (16+)
**23.30** х/ф **«Красивый и упрямый»**. (12+)
**2.30** х/ф **«Не ходите, девки, замуж»**. (0+)
**3.35** д/с «Чудотворица». (16+)
**6.00** «Домашняя кухня». (16+)

### РЕН-ТВ

**5.00, 4.15** «Территория заблуждений» с Игорем Прокопенко. (16+)
**6.00, 9.00** Документальный проект. (16+)
**7.00** «С бодрым утром!» (16+)
**8.30, 12.30, 16.30, 19.30** Новости. (16+)
**12.00, 16.00, 19.00** «Информационная программа 112». (16+)
**13.00** «Загадки человечества с Олегом Шишкиным». (16+)
**14.00** Засекреченные списки. (16+)
**17.00** «Тайны Чапман». (16+)
**18.00, 3.30** «Самые шокирующие гипотезы». (16+)
**20.00, 21.00** Документальный спецпроект. (16+)
**23.00** х/ф **«Блэйд»**. (18+)
**1.20** х/ф **«V» значит Вендетта»**. (16+)

### ТНТ

**7.00** THT. Gold. (16+)
**9.00, 23.00** «Дом-2». (16+)
**11.30** «Бородина против Бузовой». (16+)
**12.30** Дом-2. Спаси свою любовь. (16+)
**13.30** т/с **«СашаТаня»**. (16+)
**15.00** т/с **«Универ. Новая общага»**. (16+)
**17.00** т/с **«Интерны»**. (16+)
**20.00** Comedy Woman. (16+)
**21.00** Комеди Клаб. (16+)
**22.00** «Комик в городе». (16+)
**1.10** «Такое кино!» (16+)
**1.40** «Stand Up». (16+)
**3.30** «Открытый микрофон». (16+)
**5.35** THT. Best. (16+)

### СТС

**6.00, 5.35** Ералаш. (0+)
**6.25** м/с **«Да здравствует король Джулиан!»** (6+)
**7.10** м/с **«Приключения Вуди и его друзей»**. (0+)
**7.30** т/с **«Мамы чемпионов»**. (16+)
**9.35** х/ф **«Агенты А.Н.К.Л.»** (16+)
**11.55** х/ф **«Шпион, который меня кинул»**. (16+)
**14.15** «Уральские пельмени». (16+)
**15.15, 19.30** «Шоу «Уральских пельменей». (16+)
**18.30** «Дело было вечером». (16+)
**21.00** х/ф **«План игры»**. (12+)
**23.15** х/ф **«Обитель зла. Возмездие»**. (18+)
**1.00** х/ф **«Привидение»**. (16+)
**3.10** х/ф **«Квартирка Джо»**. (12+)
**4.20** т/с **«Два отца и два сына»**. (16+)

### 5 КАНАЛ

**5.00, 9.00, 13.00** «Известия».
**5.25** д/с «Страх в твоем доме». (16+)
**6.50, 9.25** т/с **«Гаишники»**. (16+)
**11.20, 13.25** т/с **«При загадочных обстоятельствах»**. (16+)
**19.15** т/с **«След»**. (16+)
**1.25** т/с **«Детективы»**. (16+)

### МАТЧ-ТВ

**6.00** д/с «Вся правда про...» (12+)
**6.30** «Ген победы». (12+)
**7.00, 8.55, 11.20, 13.50, 18.50, 20.00** Новости.
**7.05, 11.25, 15.10, 20.05, 23.30** Все на Матч!
**9.00** Автоспорт. Ралли-рейд «Шелковый путь». (0+)
**9.20** Волейбол. Россия - Франция. Лига наций. «Финал 6-ти». Мужчины. (0+)
**11.55** Формула-1. Гран-при Великобритании. Свободная практика. Прямая трансляция.
**13.30, 18.30, 23.10, 2.20, 3.20** Специальный репортаж. (12+)
**13.55, 18.55** Художественная гимнастика. Многоборье. Летняя Универсиада-2019. Прямая трансляция.
**15.30** Смешанные единоборства. One FC. Прямая трансляция.
**20.55** Водное поло. Летняя Универсиада-2019. Женщины. 1/2 финала. Прямая трансляция.
**22.10** Все на футбол! (12+)
**0.30** Летняя Универсиада-2019. (0+)
**2.50** «Команда мечты». (12+)
**3.50** Волейбол. Лига наций. «Финал 6-ти». Мужчины. Россия - США. Прямая трансляция.

### ОТР

**5.00, 11.05** «За дело!» (12+)
**5.55, 12.05** «Большая страна». (12+)
**6.20** «Дом «Э». (12+)
**6.50** м/ф **«Приключения Болека и Лелека»**. (0+)
**7.00, 15.10** т/с **«Семья Светофоровых»**. (12+)
**7.25** «Вспомнить всё». (12+)
**7.50** д/ф «Совершенно секретно. Лев Яшин. Судьба вратаря». (12+)
**8.35** м/ф **«Аленький цветочек»**. (0+)
**9.15, 22.10** т/с **«Агент особого назначения-3»**. (12+)
**10.55** м/ф **«Лиса-строитель»**. (0+)
**12.00, 13.00, 15.00** Новости.
**12.30** «Гамбургский счет». (12+)
**13.10, 18.00, 0.30** ОТРажение.
**15.40** «Медосмотр». (12+)
**15.50** х/ф **«Над Тиссой»**. (12+)
**17.10** «Культурный обмен». (12+)
**21.05** «Моя история». (12+)
**21.45** д/с «Тайны разведки». (12+)
**23.50** д/с «Послушаем вместе». (12+)

## Шимбә, 13 июль

### 1 КАНАЛ

**5.00, 6.10** т/с **«Сезон любви»**. (12+)
**6.00** Новости.
**9.00** «Играй, гармонь любимая!» (12+)
**9.45** «Слово пастыря». (0+)
**10.00, 12.00** Новости с субтитрами.
**10.15** д/ф «Египетская сила Бориса Клюева». К юбилею артиста. (12+)
**11.10** «Честное слово» с Юрием Николаевым. (12+)
**12.15, 4.50** д/ф «Теория заговора». (16+)
**13.00** д/ф «Александр Абдулов. Жизнь на большой скорости». (16+)
**15.00** х/ф **«Карнавал»**. (0+)
**18.00** «Кто хочет стать миллионером?» с Дмитрием Дибровым. (12+)
**19.30, 21.20** «Сегодня вечером». (16+)
**21.00** Время.
**23.00** Международный музыкальный фестиваль «Белые ночи» Санкт-Петербурга». (12+)
**1.00** х/ф **«Дьявол носит Prada»**. (14+)
**3.00** «Про любовь». (16+)
**4.05** «Наедине со всеми». (16+)

### РОССИЯ 1

**5.00** «Утро России. Суббота».
**8.15** «По секрету всему свету».
**8.40** Местное время. Суббота. (12+)
**9.20** «Пятеро на одного».
**10.10** «Сто к одному». Телеигра.
**11.00, 14.00, 20.00** Вести.
**11.20** Вести-Татарстан.
**11.40** «Юмор! Юмор! Юмор!!!» (16+)
**14.20** «Далекие близкие» с Борисом Корчевниковым. (12+)
**15.25, 20.30** т/с **«Девичник»**. (12+)
**0.40** «Выход в люди». (12+)
**1.45** х/ф **«Алла в поисках Аллы»**. (12+)

### ТНВ

**5.00** т/с **«Бәхетлеме син?»**. (12+)
**7.00** «Сабантуй маҗаралары». (6+)
**9.00** Мультфильмы. (0+)
**9.30** «Адәм белән һава». (6+)
**10.00** «Кайнар хит». (12+)
**11.00** д/ф «Тарихлы шәһәрләр буенча сәяхәт». (12+)
**11.30** «Секреты татарской кухни». (12+)
**12.00** «Каравай». (6+)
**12.30** «Видеоспорт». (12+)
**13.00** «Канун. Парламент. Җәмгыять». (12+)
**13.30** «Татар халык җырлары». (0+)
**14.00** «Йөрәктән - йөрәккә». (6+)
**15.00** «Мин». (12+)
**15.30** «Юлчы». (6+)
**16.00** И. Зәйниев. «Бәби». Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры спектакле. (12+)
**18.00** «Кәмит Җәвит» Юмористик тапшыру. (16+)
**19.00** «Халкым минем...». (12+)
**19.30, 21.30** Новости в субботу. (12+)
**20.00** «Ватадашлар». (12+)
**20.30** «Җырлыйк әле!» (6+)
**22.00** х/ф **«Бессмертная возлюбленная»**. (0+)
**0.05** «Мин бу җирне матурларга тудым» Әнгам Атнабаев иҗатына багышланган кичә. (6+)
**2.05** т/с **«Тапшырылмаган хатлар»**. (6+)
**3.40** «Караоке бәйге». (6+)
**4.30** «Оныта алмыйм» Ретро-концерт. (0+)

### ТАТАРСТАН 24

**0.00, 1.00, 2.00, 3.00, 4.00, 5.00, 6.00, 7.00, 8.00, 9.00, 10.00, 11.00, 12.00, 13.00, 14.00, 15.00, 16.00, 17.00, 18.00, 19.00, 20.00, 21.00, 22.00, 23.00** Новости Татарстана-24. (16+)
**0.30, 1.30, 2.30, 3.30, 4.30, 5.30** Главные новости. (16+)
**6.30, 7.30, 8.30, 9.30, 10.30** Самобытные культуры. (16+)
**11.30** Мобильный репортер. (16+)
**12.30, 17.30** Суть недели с Григорием Тинским. (16+)
**13.30, 22.30** Главное за неделю. (16+)
**14.30, 19.30** Суть дела. Итоги с Григорием Тинским. (16+)
**15.30, 21.30** INews за неделю. (16+)
**16.30, 20.30** Хроника происшествий. (16+)
**16.50, 20.50** Крутящий момент. (16+)
**18.30** Интервью без галстука. (16+)
**23.30** Мобильный репортер за неделю. (16+)

### ТВЦ

**5.50** Марш-бросок. (12+)
**6.20** х/ф **«Тень у пирса»**. (0+)
**8.05** Православная энциклопедия. (6+)
**8.35** д/ф «Горькие слезы советских комедий». (12+)
**9.25** х/ф **«Мой любимый призрак»**. (12+)
**11.30, 14.30, 23.55** События.
**11.45** «Юмор летнего периода». (12+)
**12.55, 14.45** х/ф **«Не в деньгах счастье»**. (12+)
**17.15** х/ф **«Улыбка Лиса»**. (12+)
**21.00** «Постскриптум» с Алексеем Пушковым.
**22.10** д/ф «90-е. Выпить и закусить». (16+)
**23.00** «Прощание. Юрий Андропов». (16+)
**0.05** «Право голоса». (16+)
**3.25** «Сила трубы». Спецрепортаж. (16+)
**3.50** д/ф «90-е. Граждане барыги!» (16+)
**4.30** д/ф «Удар властью. Виктор Черномырдин». (16+)
**5.10** д/ф «Увидеть Америку и умереть». (12+)

### НТВ

**4.50** х/ф **«Белый Бим, черное ухо»**. (0+)
**8.00, 10.00, 16.00, 19.00** Сегодня.
**8.20** Готовим с Алексеем Зиминым. (0+)
**8.55** «Кто в доме хозяин?» (12+)
**9.30** Едим дома. (0+)
**10.20** Главная дорога. (16+)
**11.00** «Еда живая и мертвая». (12+)
**12.00** Квартирный вопрос. (0+)
**13.10** Поедем, поедим! (0+)
**14.00** Своя игра. (0+)
**16.20** Следствие вели... (16+)
**19.25** т/с **«Пес»**. (16+)
**23.40** «Международная пилорама» с Тиграном Кеосаяном. (18+)
**0.30** «Квартирник НТВ у Маргулиса». (16+)
**1.20** «Фоменко фейк». (16+)
**1.40** Дачный ответ. (0+)
**2.30** д/с ««Таинственная Россия». (16+)
**3.15** х/ф **«Холодное лето пятьдесят третьего...»** (12+)

### КУЛЬТУРА

**6.30** Библейский сюжет.
**7.05** м/ф **«Малыш и Карлсон», «Карлсон вернулся»**.
**7.50** х/ф **«Волшебный голос Джельсомино»**.
**10.00** д/с «Передвижники».
**10.30** х/ф **«В погоне за славой»**.
**11.55** «Больше, чем любовь».
**12.40** д/с «Культурный отдых».
**13.10, 1.20** д/ф «Дикая природа островов Индонезии».
**14.05** Фрайбургский барочный оркестр играет Моцарта.
**15.40** «Линия жизни».
**16.30** х/ф **«Пловец»**.
**17.40** д/с «Предки наших предков».
**18.20** Мой серебряный шар.
**19.05** х/ф **«Трактористы»**.
**20.30** д/ф «Мозг. Вторая вселенная».
**21.55** х/ф **«Вестсайдская история»**.
**0.20** Жан-Люк Понти и его бэнд.
**2.20** м/ф **«Великая битва Слона с Китом». «Перевал»**.

### ДОМАШНИЙ

**6.30** «6 кадров». (16+)
**6.45** «Удачная покупка». (16+)
**6.55** д/с «Из России с любовью». (16+)
**7.55, 2.55** х/ф **«Формула любви»**. (0+)
**9.45** х/ф **«Паутинка бабьего лета»**. (14+)
**11.35** х/ф **«Самая красивая»**. (12+)
**15.15** х/ф **«Самая красивая-2»**. (14+)
**19.00** х/ф **«Личное пространство»**. (12+)
**23.30** т/с **«Повороты судьбы»**. (16+)
**4.20** д/с «Чудотворица». (16+)
**5.55** «Домашняя кухня». (16+)

### РЕН-ТВ

**5.00, 16.20, 3.50** «Территория заблуждений» с Игорем Прокопенко. (16+)
**7.30** х/ф **«Ангелы Чарли»**. (0+)
**9.15** «Минтранс». (16+)
**10.15** «Самая полезная программа». (16+)
**11.15** «Военная тайна» с Игорем Прокопенко. (16+)
**18.20** Засекреченные списки. (16+)
**20.30** х/ф **«Враг государства»**. (0+)
**23.00** х/ф **«В ловушке времени»**. (12+)
**1.10** х/ф **«Огонь на поражение»**. (12+)
**3.00** «Самые шокирующие гипотезы». (16+)

### ТНТ

**7.00** THT. Gold. (16+)
**8.00, 1.05** THT Music. (16+)
**9.00, 23.00** «Дом-2». (16+)
**11.00** Где логика? (16+)
**14.00** Комеди Клаб. (16+)
**18.00** х/ф **«Сумерки»**. (14+)
**20.30** х/ф **«Сумерки. Сага. Новолуние»**. (12+)
**1.40** «Открытый микрофон». (16+)
**5.05** THT. Best. (16+)

### СТС

**6.00** Ералаш. (0+)
**6.50** м/с **«Приключения Кота в сапогах»**. (6+)
**7.15** м/с **«Спирит. Дух свободы»**. (6+)
**7.40** м/с **«Три кота»**. (0+)
**8.05** м/с **«Том и Джерри»**. (0+)
**8.30** «Детский КВН». (6+)
**9.30** «ПроСТО кухня». (12+)
**10.30** «Рогов. Студия 24». (16+)
**11.30** х/ф **«Привидение»**. (16+)
**14.15** х/ф **«Поездка в Америку»**. (0+)
**16.35** х/ф **«План игры»**. (12+)
**18.55** х/ф **«Золушка»**. (0+)
**21.00** х/ф **«Принц Персии. Пески времени»**. (12+)
**23.20** х/ф **«Обитель зла. Последняя глава»**. (18+)
**1.15** х/ф **«Обитель зла. Возмездие»**. (18+)
**2.50** х/ф **«Няня»**. (0+)
**4.15** т/с **«Два отца и два сына»**. (16+)

### 5 КАНАЛ

**5.00** т/с **«Детективы»**. (16+)
**10.45** т/с **«След»**. (16+)
**0.45** Светская хроника. (16+)

### МАТЧ-ТВ

**6.00** Синхронное плавание. Чемпионат мира по водным видам спорта. Микст. Техническая программа. Прямая трансляция.
**6.30** Специальный репортаж. (12+)
**6.55** Синхронные прыжки в воду. Чемпионат мира по водным видам спорта. Смешанные команды. Вышка. Финал. Прямая трансляция.
**8.30, 11.20, 21.20, 23.50** Все на Матч!
**9.00** Автоспорт. Ралли-рейд «Шелковый путь». (0+)
**9.20, 11.15, 14.30, 17.00, 21.15** Новости.
**9.25** Прыжки в воду. Чемпионат мира по водным видам спорта. Женщины. Трамплин 1 м. Финал. Прямая трансляция.
**10.45** д/с «Капитаны». (12+)
**11.55** Автоспорт. Российская серия кольцевых гонок. «Казань Ринг». Туринг. Прямая трансляция.
**13.00** Синхронное плавание. Соло. Чемпионат мира по водным видам спорта. Техническая программа. Финал. Прямая трансляция.
**14.40** Синхронные прыжки в воду. Чемпионат мира по водным видам спорта. Мужчины. Трамплин 3 м. Финал. Прямая трансляция.
**15.55** Формула-1. Гран-при Великобритании. Квалификация. Прямая трансляция.
**17.10** Все на футбол!
**18.15** Футбол. «Спартак» (Москва) - «Сочи». Российская Премьер-лига. Прямая трансляция.
**21.50** Смешанные единоборства. Bellator. (16+)
**0.50** Волейбол. Лига наций. Мужчины. «Финал 6-ти». 1/2 финала. Прямая трансляция.
**2.55** Спортивный календарь. (12+)
**3.05** Смешанные единоборства. One FC. (16+)
**5.05** Водное поло. Россия - Канада. Чемпионат мира по водным видам спорта. Женщины. Прямая трансляция.

### ОТР

**4.30, 21.35** Концерт «Русский романс. Лучшие голоса мира». (12+)
**6.20, 23.25** х/ф **«Проводы белых ночей»**. (12+)
**7.50, 12.40** д/с «Моменты судьбы». (6+)
**8.00** «Служу Отчизне». (12+)
**8.25, 12.50** «Среда обитания». (12+)
**8.40** «От прав к возможностям». (12+)
**8.55** «Истинная роль». (12+)
**9.20** «За дело!» (12+)
**10.15** д/с «Земля-2050». (12+)
**10.40** д/с «Охотники за сокровищами». (12+)
**11.05, 19.20** «Культурный обмен». (12+)
**11.45, 3.00, 3.45** д/ф «Смех и слезы Сергея Филиппова». (12+)
**13.00, 15.00, 19.00** Новости.
**13.05, 15.05** т/с **«Четыре танкиста и собака»**. (6+)
**17.00** «Большая наука». (12+)
**17.25** «Новости Совета Федерации». (12+)
**17.40** х/ф **«Над Тиссой»**. (12+)
**20.00** х/ф **«Психи на воле»**. (12+)
**0.55** х/ф **«Граффити»**. (14+)



Безнен МИРАС
тарихи, әдәби, сәнгати, дини мирас • татар гаме • төрки дөнья • тел • хәтер
ИНДЕКС: Татарстанда – П-2343
Россиядә – 70275 (П-7074)
beznenmiras.ru
facebook.com/beznenmiras
instagram.com/beznenmiras
12+
реклама

## Якшәмбе, 14 июль

### 1 КАНАЛ

**5.50, 6.10** х/ф **«Сыщик петербургской полиции»**. (0+)
**6.00** Новости.
**7.40** «Часовой». (12+)
**8.10** «Здоровье». (16+)
**9.20** «Непутевые заметки» с Дмитрием Крыловым. (12+)
**10.00, 12.00** Новости с субтитрами.
**10.15** «Жизнь других». (12+)
**11.10, 12.15** «Видели видео?» (6+)
**13.00** «Живая жизнь». (12+)
**15.00** д/ф «Свадьба в Малиновке». Непридуманные истории». (16+)
**16.00** х/ф **«Свадьба в Малиновке»**. (0+)
**17.50** «Точь-в-точь». (16+)
**21.00** Время.
**21.30** т/с **«Лучше, чем люди»**. Новые серии. (16+)
**23.30** Международный музыкальный фестиваль «Белые ночи» Санкт-Петербурга». (12+)
**1.30** х/ф **«Скандальный дневник»**. (16+)
**3.10** «Про любовь». (16+)
**4.05** «Наедине со всеми». (16+)

### РОССИЯ 1

**5.05** т/с **«Сваты»**. (12+)
**7.20** «Семейные каникулы».
**7.30** «Смехопанорама».
**8.00** Утренняя почта.
**8.40** Местное время. Воскресенье.
**9.20** «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
**10.10** «Сто к одному». Телеигра.
**11.00, 20.00** Вести
**11.20** «Смеяться разрешается».
**13.55** х/ф **«Если бы да кабы»**. (12+)
**16.10** х/ф **«Любовь говорит»**. (12+)
**21.00** Москва. Кремль. Путин.
**21.40** «Воскресный вечер с Владимиром Соловьевым». (12+)
**1.00** д/ф «Год после Сталина». (16+)
**2.05** х/ф **«Клинч»**. (16+)
**3.50** т/с **«Гражданин начальник»**. (16+)

### ТНВ

**5.00** т/с **«Тузган торактан күчкәндә»**. (12+)
**8.00** «Бер очрашу - бер гомер» Резидә Шәрәфиева. (6+)
**8.30** м/с **«Радость восхождения»**. (6+)
**9.00** «Здоровая семья: мама, папа и я». (6+)
**9.15** «Тамчы-шоу». (0+)
**9.45** «Яшьләр тукталышы». (12+)
**10.15** «Мин». (12+)
**10.45** Концерт. (6+)
**11.30** «Секреты татарской кухни». (12+)
**12.00** «Каравай». (6+)
**12.30** «Закон. Парламент. Общество». (12+)
**13.00** «Яратып яшик!» Раяз Фасихов концерты. (6+)
**15.00** «Ком сәгате». (12+)
**16.00** «Җырлыйк әле!» (6+)
**17.00** «Видеоспорт». (12+)
**17.30** «Әдәби хәзинә». (12+)
**18.00** «Башваткыч». (6+)
**19.00, 22.00** «Семь дней». (12+)
**20.00** «Черное озеро». (16+)
**20.30** «Болгар радиосы» концерты. (6+)
**21.00** «Әй, язмыш, язмыш...». (12+)
**23.00** х/ф **«Сөю көтә йөрәк»**. (12+)
**0.30** х/ф **«Дикарь»**. (16+)
**2.00** «Манзара». (6+)
**3.40** «Караоке бәйге». (6+)
**4.30** «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт. (0+)

### ТАТАРСТАН 24

**0.00, 1.00, 2.00, 3.00, 4.00, 5.00, 6.00, 7.00, 8.00, 9.00, 10.00, 11.00, 12.00, 13.00, 14.00, 15.00, 16.00, 17.00, 18.00, 19.00, 20.00, 21.00, 22.00, 23.00** Новости Татарстана-24. (16+)
**0.30, 1.30, 2.30, 3.30, 4.30, 5.30, 14.30, 21.30** Главное за неделю. (16+)
**6.30, 7.30, 8.30, 9.30** Великие сражения: кровь и сталь. (16+)
**10.30** Око прокурора. (16+)
**10.45, 15.30, 20.30** Хроника происшествий. (16+)
**11.30, 17.30** INews за неделю. (16+)
**12.30, 19.30** Мобильный репортер за неделю. (16+)
**13.30** Интервью без галстука. (16+)
**15.50, 20.50** Крутящий момент. (16+)
**16.30, 22.30** Суть недели с Григорием Тинским. (16+)
**18.30, 23.30** Суть дела. Итоги с Григорием Тинским. (16+)

### ТВЦ

**5.55** х/ф **«Чужая родня»**. (0+)
**7.55** «Фактор жизни». (12+)
**8.30** Петровка, 38. (16+)
**8.45** х/ф **«Беглецы»**. (12+)
**10.40** «Спасите, я не умею готовить!» (12+)
**11.30, 0.25** События.
**11.45** х/ф **«Дело «Пестрых»**. (0+)
**13.50** «Смех с доставкой на дом». (12+)
**14.30** Московская неделя.
**15.05** д/с «Свадьба и развод». (16+)
**15.55** «Хроники московского быта. Поздний ребенок». (12+)
**16.40** «Хроники московского быта. «Левые» концерты». (12+)
**17.30** х/ф **«Отель счастливых сердец»**. (12+)
**21.25, 0.40** т/с **«Месть на десерт»**. (12+)
**2.00** х/ф **«Идеальное убийство»**. (16+)
**3.30** х/ф **«Нарушение правил»**. (12+)

### НТВ

**4.50** х/ф **«Я шагаю по Москве»**. (0+)
**6.00** х/ф **«Мимино»**. (12+)
**8.00, 10.00, 16.00, 19.00** Сегодня.
**8.20** «У нас выигрывают!» (12+)
**10.20** Первая передача. (16+)
**11.00** Чудо техники. (12+)
**11.50** Дачный ответ. (0+)
**13.00** «НашПотребНадзор». (16+)
**14.00** «Секрет на миллион». (16+)
**16.20** Следствие вели... (16+)
**19.35** т/с **«Пес»**. (16+)
**23.40** х/ф **«Криминальный квартет»**. (16+)
**1.30** т/с **«Ментовские войны»**. (16+)
**4.30** т/с **«Адвокат»**. (16+)

### КУЛЬТУРА

**6.30** д/с «Человек перед Богом».
**7.00** м/ф **«Тайна третьей планеты». «Щелкунчик»**.
**8.15** х/ф **«Незнайка с нашего двора»**.
**10.25** «Обыкновенный концерт с Эдуардом Эфировым».
**10.55** х/ф **«Вестсайдская история»**.
**13.20** д/ф «Дикая природа островов Индонезии».
**14.15** д/с «Карамзин. Проверка временем».
**14.45** д/с «Первые в мире».
**15.00, 23.35** х/ф **«Трембита»**.
**16.30** д/с «Пешком...»
**17.00, 1.05** «Искатели».
**17.50** д/ф «Неукротимый Гилельс».
**18.30** «Романтика романса».
**19.30** Новости культуры с Владиславом Флярковским.
**20.10** х/ф **«Не сошлись характерами»**.
**21.30** Шедевры мирового музыкального театра.

*Профилактика на канале с 2.00 до 3.00.*

### ДОМАШНИЙ

**6.30** «6 кадров». (16+)
**6.35** «Удачная покупка». (16+)
**6.45** д/с «Из России с любовью». (16+)
**7.45** х/ф **«Не ходите, девки, замуж»**. (0+)
**9.05** х/ф **«Вальс-бостон»**. (12+)
**11.00** х/ф **«Украденная свадьба»**. (16+)
**14.35** т/с **«Прошу поверить мне на слово»**. (16+)
**19.00** т/с **«Память сердца»**. (16+)
**23.00** т/с **«Повороты судьбы»**. (16+)
**2.30** х/ф **«Паутинка бабьего лета»**. (14+)
**4.00** д/с «Чудотворица». (16+)
**5.35** «Домашняя кухня». (16+)

### РЕН-ТВ

**5.00** «Территория заблуждений» с Игорем Прокопенко. (16+)
**6.40** х/ф **«Плохая компания»**. (14+)
**8.45** х/ф **«Враг государства»**. (0+)
**11.15** х/ф **«В ловушке времени»**. (12+)
**13.30** т/с **«Игра престолов»**. (16+)
**0.00** «Соль». (16+)
**2.30** «Военная тайна» с Игорем Прокопенко. (16+)

### ТНТ

**7.00** ТНТ. Gold. (16+)
**9.00, 23.00** «Дом-2». (16+)
**11.00** Перезагрузка. (16+)
**12.00** х/ф **«Сумерки»**. (14+)
**14.30** х/ф **«Сумерки. Сага. Новолуние»**. (12+)
**17.05** Комеди Клаб. (16+)
**22.00** «Stand Up». (16+)
**1.05** «Такое кино!» (16+)
**1.40** ТНТ Music. (16+)
**2.10** «Открытый микрофон». (16+)
**5.35** ТНТ. Best. (16+)

### СТС

**6.00, 5.20** Ералаш. (0+)
**6.50** м/с **«Приключения Кота в сапогах»**. (6+)
**7.15** м/с **«Спирит. Дух свободы»**. (6+)
**7.40** м/с **«Три кота»**. (0+)
**8.05** м/с **«Царевны»**. (0+)
**8.30** «Детский КВН». (6+)
**9.30** «Шоу «Уральских пельменей». (16+)
**10.45** х/ф **«Няня»**. (0+)
**12.40, 2.10** х/ф **«Однажды в Вегасе»**. (14+)
**14.40** х/ф **«Золушка»**. (0+)
**16.45** х/ф **«Принц Персии. Пески времени»**. (12+)
**19.05** м/ф **«Мегамозг»**. (0+)
**21.00** х/ф **«Одинокий рейнджер»**. (12+)
**0.00** х/ф **«Поездка в Америку»**. (0+)
**3.45** т/с **«Два отца и два сына»**. (16+)

### 5 КАНАЛ

**5.00** Светская хроника. (16+)
**6.30** «Сваха». (16+)
**7.05** «Вся правда о... колбасе». (12+)
**8.00** Неспроста. (12+)
**9.00** д/с «Моя правда». (16+)
**10.00** т/с **«Глухарь»**. (16+)
**3.15** «Большая разница». (16+)

### МАТЧ-ТВ

**6.00** Водное поло. Россия - Канада. Чемпионат мира по водным видам спорта. Женщины. Прямая трансляция.
**6.15** «Сделано в Великобритании». (16+)
**7.30** Волейбол. Лига наций. Мужчины. «Финал 6-ти». 1/2 финала. (0+)
**9.30, 1.20** Специальный репортаж. (12+)
**10.00, 11.50, 14.30, 18.15** Новости.
**10.10** Автоспорт. Ралли-рейд «Шелковый путь». (0+)
**10.30, 18.20, 23.55** Все на Матч!
**11.20** «Гран-при» с Алексеем Поповым». (12+)
**11.55** Автоспорт. Российская серия кольцевых гонок. «Казань Ринг». Туринг. Прямая трансляция.
**13.00** Синхронное плавание. Дуэты. Чемпионат мира по водным видам спорта. Техническая программа. Финал. Прямая трансляция.
**14.40** Синхронные прыжки в воду. Чемпионат мира по водным видам спорта. Женщины. Вышка. Финал. Прямая трансляция.
**16.00** Формула-1. Гран-при Великобритании. Прямая трансляция.
**18.55, 21.55** Футбол. Кубок африканских наций-2019. 1/2 финала. Прямая трансляция.
**20.55** «После футбола» с Георгием Черданцевым.
**0.50** «Кибератлетика». (16+)
**1.50** Волейбол. Лига наций. Мужчины. «Финал 6-ти». Финал. Прямая трансляция.
**3.55** Летняя Универсиада-2019. Церемония закрытия. (0+)

### ОТР

**4.30, 23.40** «Звук». Группа Two Siberians. (12+)
**5.30** «Вспомнить всё». (12+)
**5.55** х/ф **«Над Тиссой»**. (12+)
**7.20, 16.50** д/ф «#ЯбСмог». (12+)
**8.00** д/с «Легенды Крыма». (12+)
**8.25** «Среда обитания». (12+)
**8.40** д/с «Курская дуга. Максимальный масштаб». (12+)
**8.55** «Истинная роль». (12+)
**9.20** х/ф **«Психи на воле»**. (12+)
**11.05, 19.20** «Моя история». (12+)
**11.45** д/ф «Смех и слезы Сергея Филиппова». (12+)
**12.30** «Гамбургский счет». (12+)
**13.00, 15.00, 19.00** Новости.
**13.05, 15.05** т/с **«Четыре танкиста и собака»**. (6+)
**17.30, 3.10** х/ф **«Проводы белых ночей»**. (12+)
**20.00** т/с **«Агент особого назначения-3»**. (12+)
**21.35** х/ф **«Граффити»**. (14+)
**0.40** д/ф «Совершенно секретно. Лев Яшин. Судьба вратаря». (12+)
**1.25** Концерт «Русский романс. Лучшие голоса мира». (12+)
**4.40** м/ф **«Машенькин концерт»**. (0+)
**4.50** м/ф **«Олень и волк»**. (0+)

Программаны «Сервис–ТВ» АҖ тәкъдим итте






### УВЕДОМЛЕНИЕ

В соответствии со ст. 62 Избирательного кодекса Республики Татарстан №21-ЗРТ от 07.05.2007 редакция газеты «Атна вакыйгалары» (свидетельство о регистрации СМИ ПИ № ТУ 16 - 01140 от 09.01.2014г.) информирует, что общий объем бесплатной печатной площади, предоставляемой для проведения предвыборной агитации, в период с 10.08.2019 и до 0 часов 07.09.2019 составляет 4176 кв.см.

Жеребьевка по распределению предоставляемой бесплатной печатной площади и заключение договоров на размещение предвыборной агитации состоится **05.08.2019г. в 10:00 часов** в помещении редакции по адресу: РТ, г. Казань, ул. Декабристов, д. 2, 13 этаж. Телефон: **(843) 222-0-999, доб.1304** Латипов Рамис Нурмухамматович.

Реклама

### УВЕДОМЛЕНИЕ

В соответствии со ст. 62 Избирательного кодекса Республики Татарстан №21-ЗРТ от 07.05.2007 редакция газеты «Атна вакыйгалары» (свидетельство о регистрации СМИ ПИ № ТУ 16 - 01140 от 09.01.2014г.) информирует, что стоимость печатной площади, предоставляемой для размещения предвыборной агитации, в период с 10.08.2019 и до 0 часов 07.09.2019 составляет 458 руб. за 1 кв.см. (кроме первой полосы).

Жеребьевка по распределению предоставляемой платной печатной площади и заключение договоров на размещение предвыборной агитации состоится **05.08.2019г. в 10:00 часов** в помещении редакции по адресу: РТ, г. Казань, ул. Декабристов, д. 2, 13 этаж. телефон: **(843) 222-0-999, доб.1304** Латипов Рамис Нурмухамматович.

Реклама




# Рамил Баһавиев:
# «Укый да, ял да итә белергә кирәк»

Унберенче сыйныфка кадәр татар телендә белем алган Казан укучысы Бердәм дәүләт имтиханнарында 399 балл җыйды.



А.Эшкинин фотолары

ҮТКӘН АТНАДА КАЗАНДА БЕРЕНЧЕ ТАПКЫР ШӘҺӘР КҮЛӘМЕНДӘ ЧЫГАРЫЛЫШ КИЧӘСЕ УЗДЫРЫЛДЫ. АНДА БАШКАЛА МӘКТӘПЛӘРЕН ТӘМАМЛАГАН 5,7 МЕҢ УКУЧЫ КАТНАШТЫ. МӘКТӘП УКУЧЫЛАРЫ ИСЕМЕННӘН РАМИЛ БАҺАВИЕВ ЧЫГЫШ ЯСАДЫ.

Алинә АЙДАРОВА

### УНИКАЛЬ ОЧРАК

БДИ җиткәч, чыгарылыш сыйныф укучылары бик борчыла. Алга таба нинди һөнәр сайлавың, кайсы уку йортына керүең шуның нәтиҗәләренә дә бәйле бит.

Казанның Ш.Мәрҗани исемендәге 2нче татар гимназиясе укучысы **Рамил Баһавиевка** югары уку йортына ничек керермен, дип баш ватасы юк. Ул быел дүрт фәннән имтиханнарда 399 балл җыйган: рус телен, информатика һәм физиканы – 100, ә математиканы 99 баллга тапшырган.

– Бу – уникаль очрак. I-XI сыйныфларда татар телендә белем алган бала чыгарылыш имтиханнарын иң югары балларга тапшырды, – диде Казанның Киров һәм Мәскәү районнары хакимияте башлыгы урынбасары **Алия Заһидуллина.**

### «ХОДАЙНЫҢ РӘХМӘТЕДЕР»


**– Рамил, сине укудагы уңышларың белән котлыйбыз! Имтиханнар тапшыру авыр булдымы?**

– Рәхмәт, әллә ни авыр булды, дип әйтә алмыйм. Әзерләнгәндә БДИ шактый катлаулы тоела. «БДИ тапшыру авыр», – дип куркытучылар да бар иде. Ләкин имтиханга кергәч, биремнәр таныш булып чыкты. Әзерләнгәннәремне искә төшереп, биремнәрнең барысын да уңышлы чиштем.

**– Ничек әзерләндең? Репетиторлар ярдәм иттеме?**

– Юк, репетиторларга мөрәҗәгать итмәдем, бары тик үз көчем белән әзерләндем. КФУ каршындагы Кече университет үткәргән лекцияләрне тыңладым, өйдә интернет ярдәмендә мисаллар чиштем. Әлбәттә, гимназия укытучылары да булышты.

**– Укучыларны БДИны бирә алмыйсыз, дип куркыталар. Моңа ничек карыйсың?**



– Укытучыларны да аңларга була: укучылар имтиханнарны тапшыра алмас, дип борчылалар. Безгә: «БДИ катлаулы, сезгә теләсә нинди бирем эләгергә мөмкин», – диләр иде. Мондый сүзләрне күбрәк ялкауларга, имтиханнарга җавапсыз караучыларга әйтәләр.

**– Имтиханга «шпаргалка» әзерләдеңме?**

– Юк, укытучылар да киңәш итмәде. Имтиханда һәр адымыңны күзәтәләр, шуңа күрә куркыта. Өстәвенә, «шпаргалка» котырып та тора бит, ягъни белсәң дә, карап аласы килә.

**– Ничек уйлыйсың, БДИны югары баллга тапшыру сәләткә бәйлеме?**

– Белмим, бәлки бу Ходайның рәхмәтедер. Шулай да көне-төне укырга, китап актарырга кирәк, димим. Вакытында укырга, вакытында күңел ачарга кирәк. Тормыш бит имтихан белән генә чикләнми. Алга таба тагын да катлаулырак сынаулар булачак.

### «ВАКЫТНЫ ДӨРЕС БҮЛҮ КИРӘК»

**– Буш вакытыңда нишлисең?**

– Музыка тыңларга яратам. Компьютерда «утыра» алам. XI сыйныфта буш вакыт күп булмады инде. Бөтен вакытымны укуга багышларга тырыштым.

**– Чиреккә «3»ле чыкканы булдымы?**

– Юк, ләкин сызым дәресеннән «4»ле чыкканы бар иде. Укытучы кырыс булдымы, үзем санга сукмыйча йөрдемме?! Анысын әйтә алмыйм, ләкин «4»ле чыкты. Шулай да еллык билге «5»ле иде.

**– Чиреккә «4»ле чыкканга кәефең кырылдымы?**

– Юк, моңа нормаль карадым. Башлангыч сыйныфта, артык хисчән булу аркасында, «5»ле алмасам, сорауларга дөрес җавап бирмәсәм, борчыла идем. Үскән саен, белгегә түгел, белемгә игътибар итәргә кирәк икәнен аңладым. Әгәр дәресләргә яхшылап әзерләнсәң, барлык биремнәрне үтәп барсаң, фәннәрне дә әйбәт үзләштерәсең.

**– Кайда укырга планлаштырасың?**

– Тормышымны фән белән бәйлисем килә. Хыялым – галим булу. Югары уку йортына килгәндә, Россиядәге (Казан, Санкт-Петербург, Мәскәү) берәр вузны сайлаячакмын. Шулай да күңелемә Казан якынрак.

**– Нинди киңәшләр бирә аласың?**

– Беренче чиратта, яхшылап әзерләнергә. Имтиханда бар белгәнеңне күрсәтергә кирәк. Күңелең тыныч булырга тиеш. Мин имтиханда тыныч булдым. Әлбәттә, борчылмадым дисәм, бу дөреслеккә туры килмәс иде. Миңа эләккән биремнәрнең күбесе таныш булып чыкты. Иренмичә, чишәргә генә кирәк.

### «ТУГАН ТЕЛНЕ САКЛЫЙК»

**– Сиңа бөтен фәннәрне дә татар телендә укытканнар. Имтиханнарга әзерләнү кыен булмадымы?**

– Мин татарча уйлыйм, татар теле – минем фикерләү телем. Шуңа күрә яңа мәгълүматны татар телендә үзләштерү миңа җиңелрәк бирелә. БДИны русча тапшырасы булгач, бары тик рус телендә генә әзерләнергә кирәк дигән сүз дөрес түгел.

**– Рамил, татарча уйлыйм, дисең. Гаиләдә татарча аралашасызмы?**

– Әйе, бары тик татарча аралашабыз. Әти-әнием – инженерлар, мин гаиләдә берданбер бара.

**– Татар телен саклап калу өчен нишләргә кирәк?**

– Һәр кеше үз өлешен кертергә тиеш. Барысы да үзебездән тора. Беренчедән, татарча аралашырга кирәк. Бирегә гаиләнең дә роле зур. Гаиләдә татарча аралашып үссәң, киләчәктә үзең корачак гаиләдә дә шулай булачак.


## Продаются нежилые помещения

**Карбышева, 6**

**ПРОДАЕТСЯ НЕЖИЛОЕ ПОМЕЩЕНИЕ №89Н, кадастровый номер 16:50:060505:0:15/190, общей площадью 159,5 кв. м, этаж цокольный №1, номера на поэтажном плане 134-146, по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Карбышева, д. 6.**

- Помещение расположено в многоквартирном кирпичном доме на цокольном этаже. Объект граничит с детским садом и многоэтажными жилыми домами. 750 метров от станции метро «Аметьево».
- Указанное помещение включает в себя 2 входные группы, 5 комнат площадью 101,8 кв. м, 8 помещений, включающих санузел, коридоры площадью 57,7 кв. м.
- Состояние - черновая отделка.
- Начальная цена реализации **4 067 633,00 руб.**
- Торговая площадка **http://sale.zakazrf.ru/NotificationEX/id/2894**

**Гаврилова, 52**

**ПРОДАЕТСЯ НЕЖИЛОЕ ПОМЕЩЕНИЕ общей площадью 346,9 кв. м, этаж 2, антресоль №2, номера на поэтажном плане 1, 1а, 2, 3, 4, 5, 5/1, 5/2, 6, 7, 7а, 7/1, 7/2, 8, 9, 12, 13, 14, 14а, кадастровый номер 16:50:110802:7134, расположенное по адресу: г. Казань, ул. Гаврилова, д. 52, пом. 1006.**

- Помещение расположено в многоквартирном кирпичном доме на втором этаже. Объект граничит с детской художественной школой, детским садом, ледовым дворцом, стадионом, многоэтажными жилыми домами.
- Состояние удовлетворительное.
- Начальная цена реализации **16 604 911,00 руб.**
- Торговая площадка **http://sale.zakazrf.ru/NotificationEX/id/2893**

Реклама

# Гөлнара Тимерҗанова: «Җырлыйм әле мин»

«Тышта буран булса булсын, өйдә буран булмасын», дип җырлаган Гөлнара Тимерҗанованы хәтерлисезме? Ул – 2000 елларда татар эстрадасы сәхнәсендә балкыган йолдызларның берсе. Аның концертлары тулы залларда алкышларга күмелеп уза иде... Ләкин тормыш без теләгәнчә генә бармый.

Алинә АЙДАРОВА

**– Гөлнара ханым, сез продюсерлык компаниясе ярдәмендә танылдыгыз, әйеме?**

– Күпләр шулай дип уйлый, ләкин бу алай түгел. Радиода җырларым яңгырый башлагач, «Мәхәббәт ялкыны» җыры танылгач, җырчы буларак күтәрелеп киткәч, танылган бер продюсерлык компаниясе мине хезмәттәшлеккә чакырды. Мин биш елга килешү төзедем. Димәк, ул вакытта популяр идем инде.

**– Сезнеңчә, бүгенге җырчыларга нәрсә җитми?**

– Ихласлык җитми, дип уйлыйм. Мәсәлән, яратып тыңлый торган җырчым бар. Ул танылган, исемен атамыйм. Тавышы бик моңлы, ләкин халык җыя ала торган җырчы түгел, чөнки ул тамашачыга салкын. Үзен бик тәкәббер тота.

*Гөлнара Тимерҗанова 1975 елның 29 маенда Башкортстанның Борай районы Чалкак авылында туган. Казан музыка училищесының һәм Казан дәүләт консерваториясенең вокал бүлекләрен тәмамлаган. «Наз», «Сөю диңгезе», «Мәхәббәт ялкыны», «Мин гомеремне багышлыйм сөюгә», «Бөек сер» һәм «Татар халык җырлары исемле» җыр дисклары дөнья күргән.*

**– Шоу-бизнес дөньясы өметләрегезне акладымы?**

– Аклады, бары тик язмыш кына авырлыклар белән сынады. Янәшәмдә ышанычлы администраторым булмады. Күп тапкырлар алдангач, үзем генә эшләргә кирәк икәнен аңладым. Продюсер да, шофер да, администратор да – үзем.

Аннан соң тавышым да юк түгел бит, өстәвенә мин – профессиональ җырчы. Шуңа күрә сәхнәне сайлавыма бер дә үкенмим.

**– Бүген җырлыйсызмы?**

– Әйе, бүген мин «Татарстанның атказанган артисты» дигән мактаулы исемгә ия җырчы буларак чыгыш ясыйм.

**– Күпләр Гөлнара Тимерҗанова кая югалды икән, ди.**

– Шулай дип сорыйлар шул. Югалмадым, тавышым да югалмады, Аллага шөкер, җырлап йөрим. Кызым тугач, күбрәк өйдә булдым. Шулай да баламны «култык астына кыстырып», барыбер чыгып китә идем.

## «МИН – БӘХЕТЛЕ, ДИП ПЫШЫЛДАП ӘЙТӘМ»

**– Гөлнара ханым, нәрсә ул бәхет?**

– Әлеге сорауны үземә дә биргәнем бар. Уз аягыңда йөрсәң, күзләрең күрсә, колагың ишетсә – бәхет шул инде ул. Аллага шөкер, ике балам бар. Бу дөньяга килеп, үзеңнән соң нәсел калдыру да бәхет.

**– Димәк, сез бәхетле?**

– «Мин бәхетле», дип әйтер өчен, билгеле бер тормыш юлын үтәргә кирәк булды. Бүген үземне бәхетле дип саныйм. Кычкырып әйтәсем килми, ә пышылдап кына. Тормыш – үзе зур имтихан икән.



С.Камалетдинов фотосы

**– Балачагыгыз ничек үтте?**

– Эшләп үстек. Әнием кырысрак кеше иде. Ни өчендер аның мине кочаклап иркәләгәнен хәтерләмим.

**– Нишләп шулай булды икән?**

– Ул өч яшеннән үги әни белән үсә. Бабайның яңа хатыны тагын өч бала таба. Әнине иркәләп тормаганнардыр. 15 яшендә урман кисәргә җибәрәләр. Ул үзе дә ана назын күрмәгән.

**– Хәзер әниегез белән мөнәсәбәтегез ничек?**

– Сагынам. Без дүрт кыз һәм бер малай үстек. Дүртебезнең һәммәсенә дә әни үз куллары белән язган догалар дәфтәре бүләк итте. Ул минем өчен зур истәлек, рәхмәт аңа! Кызганыч, еш кайта алмыйм. Әти үлгәч, әнине Казанга алып килергә теләдем. Ул, кырт кисеп, каршы булды.

Әти белән әнине сайлап алмыйлар. Дөресен әйткәндә, әле һаман да әнинең назын, аның яратып: «Кызым», – дип эндәшкәнен көтәм. Ләкин сиңа әниемне начар итеп сөйләү дөрес булмас. Әгәр дә ул безгә карата йомшаграк булса, язмышлар башка төрлерәк булыр иде кебек.

**– Казанга килгән вакытыгызны хәтерлисезме?**

– Казанга китү көнен көттем. Аны искә төшерсәң... Әти 40 сум акча бирде. Ул вакытта безнең авылдан районга автобус бәясе 3,5 сум иде. Кыскасы, кесәдә акча юк. Кая барырга, нишләргә?! Беренче тапкыр шундый ерак юлга чыгуым иде. Билет сатып алдым, бар да яхшы кебек. Ләкин контролер апа билет сорагач, карасам, билет юк! Штраф салдылар. Әй, еладым.

Яңавыл станциясенә бардым. Ул 60 чакрым ераклыкта урнашкан. Утырдым поездга. Бераз барганнан соң, егетләр бәйләнә башлады. Башка вагонга киттем. Тегеләр мине эзләп йөрде. Ярый әле бер яхшы проводник булды – ул мине үз бүлмәсенә качырды.

Казанда укырга кердем. Ай саен стипендия түләделәр. Хәзер уйлыйм: ул акчага ничек яшәгәнбездер?! Соңыннан бар да җайлана башлады. Җырлый белүемне күреп алдылар, шуңа күрә концертларга чакыралар иде.

## «ГАИЛӘНЕ САКЛАРГА ТЫРЫШТЫМ»

**– Тиз гашыйк булдыгызмы? Ирегез белән ничек таныштыгыз?**

– Әйе, танышкан көнне үк аның минем кеше булуын аңладым. Игезәкләр йолдызлыгы астында туучылар тиз гашыйк була. Бик ышанучан идем мин!

Беренче ирем оператор булып эшли иде. Агыйдел шәһәрендә уздырылган зур бәйрәмгә җырларга чакырдылар. Шул концертта таныштык. Озак йөрмәдек. Минем тизрәк кияүгә чыгасым килде, чөнки яклар кешем юк иде. Ә ирем булса, мине саклар дип уйладым. Шулай булды да, ирем миңа зур терәк иде. Һәм без бер-беребезне яраттык – бу да мөһим.

**– Аерылышуыгызның сәбәбе нидә?**

– Белмим. Минемчә, мондый хәлләр болай гына булмый, күз тигәндер дип уйлыйм. Без бит яратышып өйләнештек. Унике ел дус-тату яшәдек. Улыбыз Идел туды. Авырлыклар да булмады түгел. Ике тапкыр йөкле булып, икесендә дә баланы югалткач, стресс кичердек. Беркемгә дә бала кайгысы күрергә язмасын. Көнләшүләр дә булды... Хәзер барысы да үткәндә калды инде.

**– Аерылышкач, нинди хәлдә калдыгыз?**

– Еладым да еладым. Иң мөһиме – мин гаиләне саклап калырга теләдем.

**– Улыгыз әтисе белән аралашамы?**

– Әйе, алар аралашып торалар. Минем генә аралашкан юк.

**– Икенче тапкыр ничә елдан кияүгә чыктыгыз?**

– Бик озак сайладым. Егетләр күп иде: дәрәҗәлесе дә, акчасы күп булмаганы да. Бүгенге ирем белән 2011 елның ноябрендә машинамның җәйге көпчәген кышкысына алмаштыру өчен чиратта торганда таныштык. 2013 елда никах укыттык. Аерылышканнан соң алты ел узгач, янәдән ир хатыны булдым. Безнең яшь аермасы – җиде ел.

Аерылышкач, бары тик өйләнмәгән, баласы булмаган кешегә генә кияүгә чыгам дип сүз биргән идем. Беренче ирем аерылган кеше, шуңа күрә икенчесе өйләнмәгән булырга тиеш иде. Шулай булды да.

**– Алга таба җырларга исәп бармы?**

– Әлбәттә! Киләсе елда 45 яшьлек юбилей кичәсен үткәрәсем бар. Көчле рухлы булып яшәргә тырышырга кирәк. Беркайчан да язмышның ачы җилләреннән сыгылып төшмәдем, тик аңа каршы көрәшмәдем дә. Бүген сөйләгән хәлләрнең күбесе мин популяр чакта булды. Чак кына сынмый калуымны беркайчан беркемгә дә күрсәтмәдем. Яшендәй яшьнәп, бер кайгысыз, рәхәтләнеп яши дисеннәр өчен.

ИТ ИНТЕРТАТ 16+ Бу хакта тулырак INTERTAT.TATAR сайтында

# Иң матур авыл Сабан туе – Камышлыда



**Унынчы Бөтенроссия авыл Сабан туе быел Самара өлкәсе Камышлы районында узды. Киләсе елда милли бәйрәмне Татарстанның Мөслим районы кабул итәчәк.**

Лилия ГАДЕЛШИНА

Х Бөтенроссия авыл Сабан туе быел Татарстанга күрше Камышлы районында үткәрелде. Камышлы – Самара өлкәсендәге татарлар иң күп яши торган район. Биредә 11 мең кеше исәпләнә, аларның 6 меңе Камышлыда гомер итә. Халыкның 83 проценты – татарлар. 22 саланың 13е – татар авылы.

29 июньдә гөрләгән Сабан туена Самара өлкәсеннән, Татарстан районнарыннан гына түгел, Россиянең 26 төбәгендәге татар иҗтимагый оешмаларыннан вәкилләр кунак булып килде.

## ӘНВӘР ДАВЫДОВКА ҺӘЙКӘЛ АЧЫЛДЫ

Бәйрәм программасы Камышлы районы үзәгендә татар шагыйре Әнвәр Давыдовка һәйкәл ачу тантанасы белән башланып китте. Анда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм Самара өлкәсе губернаторы Дмитрий Азаров, шагыйрьнең Казанда яшәүче кызы Алсу Абдулҗанова, Татарстан язучылары катнашты.

**Рөстәм Миңнеханов** һәйкәл куярга булышкан барча кешегә рәхмәтен белдерде. «Самара җире татар халкына бик күп лаеклы уллар һәм кызлар үстерде. Әнвәр Давыдов та татар халкының рухи мирасына һәм илебез мәдәниятенә зур өлеш керткән шәхес», – диде ул.

– Әти 1968 елның 23 июнендә Сабан туе көнне вафат булган иде. Бүген Сабан туе көнендә ул шушы һәйкәл рәвешендә янә безнең тормышыбызга кайтты, – диде **Алсу Абдулҗанова**. Ул да әтисенең туган ягында аның хәтерен кадерләп саклаган өчен якташларына рәхмәт әйтте. Мәдәният йорты, урам язучының исемен йөртә.

Әнвәр Давыдов (1919-1968) тумышы белән – Камышлыдан. Бөек Ватан сугышы башланганда хәрби хезмәткә алынган була. Сугыштан соң район газетасында эшли. 1952 елда Казанга күчenә. Татарстан Язучылар берлеге идарәсе сәркатибе, Татарстан китап нәшриятында баш мөхәррир урынбасары булып эшли. Татар һәм рус телләрендә егермедән артык китабы чыга.

– Әнвәр Давыдов узган гасырның 50нче елларында татар шигъриятенең сыйфатын күтәргән, күп кенә яшьләрне әдәбиятка тарткан шәхес иде, – дип искә алды Татарстанның халык шагыйре **Равил Фәйзуллин.**




В.Васильев фотолары

ӘНВӘР ДАВЫДОВ БЮСТЫ САМАРА ӨЛКӘСЕ БЮДЖЕТЫ ХИСАБЫНА ЧАЛЛЫДА КОЕЛГАН. УЛ КОМПОЗИТ МАТЕРИАЛДАН ЯСАЛГАН. АВТОРЫ – ЧАЛЛЫ СЫНЧЫСЫ ВАДИМ ИКСАНОВ.



Камышлы районы – татарча Әлифба китабын төзегән галим Сәләй Вәгыйзовның (1908-2005) туган ягы. Татар Байтуганы авылында аның музей-йорты бар. Музей авыл фельдшеры Нурания Абзалова тырышлыгы һәм Татарстан Президенты ярдәме белән 2016 елда ачылды. Быел Нурания ханым Самара татарларының Фатих Мортазин исемендәге премиясенә лаек булды. Фатих Мортазин (1875-1938) – XX гасыр башында Самара мәчете имам-хатыйбы, Татар мөселман җәмгыяте рәисе булган, китапханә, китап кибете, өлкәннәрне укырга-язарга өйрәтү курслары ачкан, татарча «Икътисад» журналын чыгарган күренекле шәхес.

## ПРЕЗИДЕНТТАН – МИКРОАВТОБУС

Камышлы читендә, биек таулар итәгендә оештырылган Бөтенроссия авыл Сабан туена 30 меңгә якын кеше җыелды. Татарстан Президенты Камышлы татарларына «Форд Транзит» микроавтобусы бүләк итте. Рөстәм Миңнеханов Сабан туе кунакларын, Самара өлкәсе татарларын сәламләп, барысына да исәнлек-саулык, муллык теләде. Тантанада өлкәнең тырыш татарларына Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләре тапшырылды.

Сабан туе – татар, башкорт халкының гына түгел, милли-мәдәни үзенчәлекләрне күрсәтә торган Россия бәйрәме дә, дип искәртте Президент. «Безнең күп төбәкләрдә булганыбыз бар, әмма Камышлыда аеруча матур оештырылган», – диде ул.

Татарстанның Кукмара районы мәйданда татар милли көнкүреше белән таныштырган «Татар авылы» этнографик комплексы корып куйган иде. Шулай ук «Башкортстан» һәм «Самара» мәйданчыклары эшләде. Соңгысында Татарстан белән Самара өлкәсе җитәкчелеге ике төбәк арасында икътисади һәм мәдәни хезмәттәшлекне үстерү турындагы килешүне имзалады.

## ГУБЕРНАТОРДАН – БҮЛӘК

Губернатор **Дмитрий Азаров** та Сабан туен кабул иткән Камышлы районына машина бүләк итте. «Нива» ачкычы район башлыгы Рафаэль Баһаветдиновка тапшырылды.

Губернатор юбилей Сабан туеның Самара өлкәсендә оештырылуы белән горурлануын белдерде. Иң беренче Бөтенроссия авыл Сабан туеның да 2010 елда шушы өлкәнең Похвистнево районындагы Гали авылында үткәрелүен искә алды. Камышлы районында оештыру эшләрендә булышкан Татарстан Хөкүмәтенә, республика Президентына рәхмәт әйтте.

– Максатларыбыз уртак – илебез халкын берләштерү, халыклар арасында дуслыкны ныгыту. Сабан туе – тырыш кешеләр, хезмәт бәйрәме. Без аны һәр елны билгеләп үтәбез, бергә җыелу өчен бик матур мөмкинлек бу. Сабан туе – алга! – диде губернатор.

Дмитрий Азаров өлкәнең һәм районның милли-мәдәни, социаль-икътисади үсешенә зур өлеш керткән шәхесләренә губернаторның рәсми бүләкләрен тапшырды.

## САМАРАГА – ТАТАР АТЫ

Россия күләмендә үткәрелгән Сабан туйлары тарихында беренче тапкыр бәйрәмне оештырган төбәккә Татарстан Хөкүмәте татар аты бүләк итте. Республиканың теләге – Самара ягында татар атларын үрчетергә этәргеч бирү.

Атны Татарстанда фермер Фәрит Нәбиуллинның татар атларын үрчетү үзәге саналган «Алмакай» хуҗалыгыннан алып килделәр. Сак-Сок кушаматлы татар атын Красный Яр районындагы «Самара» агрокомплексы хуҗалыгы кабул итеп алды.

## ТӘКӘНЕ МӘДРӘСӘГӘ БИРДЕЛӘР

Сабан туенда Марий Эл егете Муса Галләмов баш батыр калды. Ул 120 килограммга кадәрге үлчәү авырлыгында көрәште. Аңа ТР Президенты исеменнән җиңел автомобиль бүләк ителде. Абсолют батыр мәйданнан машинага утырып китте, ә тәкәне Камышлы авылы мәдрәсәсенә бүләк итте.

Муса быел Казанның Аккош күле буендагы Сабан туенда да җиңү яулап, җиңел автомобиль белән бүләкләнгән иде.

## КИЛӘСЕ ЕЛДА – МӨСЛИМДӘ

Сабан туе тәмамлангач, бәйрәмнең символы – «Тулпар ат» Татарстанның Мөслим районы башлыгына тапшырылды. Рамил Муллин 2020 елда – ТАССРның 100 еллыгын билгеләп үткәндә кунакларны Мөслимдә узачак Сабан туена чакырды.

– Камышлылар Бөтенроссия авыл Сабан туйлары тарихындагы иң матур бәйрәмне үткәрде, Мөслимгә бик тә тырышырга туры киләчәк, – диде Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе **Ринат Закиров**.

Камышлы башлыгы **Рафаэль Баһаветдинов** хәбәр иткәнчә, Сабан туена кукмаралылар корып куйган «Татар авылы» этнографик комплексы районга бүләк итеп калдырылган. Анда хәзер музей ясаячаклар.

# Кәҗә белән сарыкка ияреп...

**Татарстанда «Тукай юлы» дип аталган җәяүле туристик маршрут ачылды.**



А.Эшкинин фотолары

«ТУКАЙ ЮЛЫ»НЫҢ МАКСАТЛАРЫ – ТАТАРСТАН ҺӘМ РОССИЯ ХАЛКЫН АКТИВ ЯЛГА ҖӘЛЕП ИТҮ, ТАТАР ТЕЛЕН, ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘРЕН САКЛАУ, АВЫЛЛАРДАГЫ ТАРИХИ ҺӘМ МӘДӘНИ ҺӘЙКӘЛЛӘРНЕ ТОРГЫЗУ, ТУРИСТЛАРГА ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮ АША АВЫЛДА ЭШЛЕКЛЕ АКТИВЛЫКНЫ ҮСТЕРҮ, «ТУКАЙ ЮЛЫ» ДИГӘН ЯҢА МӘДӘНИ-ТУРИСТИК БРЕНД БУЛДЫРУ.



Гөлназ ГЫЙЛФАНОВА

29 июнь көнне иртәнге сәгать 10да Арча тимер юл станциясе мәйданында яңа туристик маршрут ачылды. Бу – Татарстанның беренче җәяүле һәм велотуристик маршруты, ди аны оештыручылар. Әлеге маршрут «Тукай юлы» дип аталган яңа мәдәни-тарихи, экологик проект кысаларында булдырылган.

– Бу проект дәүләтнеке түгел, аны беркем дә финансламый. Ул бары тик татар халкының тарихын, көнкүрешен, мәдәниятен күрсәтергә, танытырга, саклап калырга теләгән кешеләрнең уртак проекты, – дип сөйләде Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, «Тукай юлы» проектының оештыру комитеты рәисе **Римма Ратникова**.

– Дөнья буйлап сәяхәт иткән вакытта шундый маршрут булдыру идеясе туды, – дип аңлатты идея авторы, Татарстанның Велосипедчылар берлеге рәисе **Илдус Янышев**. – Дөньяда җәяүлеләр өчен туристик маршрутлар бик күп бит. Ә бездә алар юк дәрәҗәсендә. Минем Россиядә дә шундый туристик маршрут булдырасым килде. Әлеге проектны әниемнең туган ягында – Арчада гамәлгә ашырырга уйладым.

Арчадан тыш, маршрут Әтнә, Балтач һәм Биектау районнары аша да уза.

– Кешеләр, җәяү йөрү дигәч, куркып кала. Табигатьнең матурлыгына сокланып барасың, саф һава сулыйсың, җиләк, гөмбә җыясың, кырларда үскән үләннәрдән чәй ясап эчәсең... Элек, совет заманында балалар, гаиләләр белән походка йөриләр иде. Хәзер дә менә шушы гадәтне кире кайтарасы килә, – ди Илдус Янышев.

**«ТУКАЙ ЮЛЫ» ДИГӘН БРЕНД БУЛДЫРАБЫЗ**

– Нигә сез проектны «Тукай юлы» дип атадыгыз, аны белүче дә аз бит, диючеләр булды. Бу – надан кешеләр сүзе! Габдулла Тукайны бөтен татар кешесе белә. Ә без кимендә – 7 миллион. Башка милләтләр дә Тукай иҗаты белән таныш, – дип саный Римма Ратникова.

Проектны тормышка ашыруда катнашучылар арасында Казан дәүләт архитектура-төзелеш университетының III курс студенты **Гадел Мөхәммәтшин** дә бар. Ул проектның логотибын, дизайнын ясаган. «Тукайның күп кенә әсәрләрен укып чыктым. «Кәҗә белән сарык» әкиятенә тукталып, логотипта аның төп геройларын куллынырга булдым», – диде Гадел.

«Тукай юлы» проектының сайты да бар. Анда маршрутка ничек әзерләнергә, нинди кием кияргә, нәрсә алырга икәнлеге турында бөтен мәгълүматны табып була.

Туристик проектны тормышка ашыруда Арча районы хакимияте дә зур тырышлык куйган. Гомумән, әлеге маршрутны ачу авылда яшәүчеләргә дә файдалы булыр, авылларыбыз тагын да матураер, инфраструктура үсәр иде, дип саный район хакимияте вәкилләре.

– Сер түгел, авылларыбызда искергән йортлар да бар, кайберләренә язгы-көзге пычракта керә дә алмыйсың. Менә бу проект тулысынча эшләп китеп, кешеләр күбрәк йөри башлагач, авылларыбыз да матураер, дип уйлыйм. Кунаклар килгәндә өйне җыештырабыз бит, монда да авыл халкы кешеләргә матур булсын дип тырышыр иде. Җирле хакимият тә эшләргә тиеш, әлбәттә – юллар салырга, чишмәләрне тәртипкә китерергә, күрсәткечләр ясарга кирәк, – диде Римма Ратникова.

Әлегә яңа маршрут буенча беренче сәяхәт кенә оештырылды: туристлар 29 июньдә Арчадан Яңа Кырлай авылына кайтты. 21 чакрымны тәшкил иткән юл Түбән Мәтәскә, Югары Мәтәскә, Мөндеш, Иске Кырлай, Яңа Иябаш, Яңа Кырлай авыллары аша узды. Киләчәктә исә маршрутта кунак йортлары, татар авылларының көнкүреше белән танышу өчен махсус мәйданчыклар, атларда йөрү мөмкинлеге булдырылачак, ди оештыручылар. Проектка Әтнә театры артистлары да кушылырга әзер. Казан белән Арча арасында автобуслар һәм электричкалар йөреп тора.



Фото – tatarstan.ru

# Татар китабы йорты туристик үзәк булачак

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Казандагы Татар китабы йортын туристик картага кертергә кушты. Башкаланың үзәгендә – Островский урамындагы ике катлы борынгы бинада Татар әдәбияты тарихы музее һәм язучы Шәриф Камалның музей-фатиры урнашкан. Шәриф Камал (1884-1942) биредә гаиләсе белән 1928-1942 елларда яшәгән. Кәрим Тинчурин, Кави Нәҗми, Гази Кашшаф, Муса Җәлил, Гадел Кутуй, Фатих Кәрим, Салих Сәйдәшев кебек татар зыялылары бу йортта еш кунак булган.

Экскурсоводлар Президентны музей экспозицияләре белән таныштырды. Быел җәй көне бинада төзекләндерү эшләре тәгәлләнде. Татар китабы йортының җитәкчесе итеп шагыйрә Луиза Янсуар билгеләнде. Биредә татар китаплары фонды тупланды, балалар һәм яшьләр иҗаты өчен аерым заллар ачылды.

**Рөстәм Миңнеханов** татар язучылары белән очрашуда яңартылган музей комплексы Казанның тагын бер туристик маршруты булырга тиеш, дип белдерде.

## КЕТЕРДӘП ТОРГАН КЫЯРЛАР

Тәмле атна

**Җырчы Лилия Хәмитова тәмле, кетердәп торган итеп кыяр тозлау ысулын өйрәтте.**



С.Камалетдинов фотосы

Хуҗабикәләр еш кына «кыяр тозлаган идем, агарды, бөтен банка атып бетте», дип зарлана. Арчада яшәп, бакчасында җиләк-җимеш, яшелчә үстерергә дә вакыт тапкан җырчы Лилия Хәмитова тозлаган кыярлар кетердәп тора.

Стерильләштерелмәгән өч литрлы банка төбенә 3 баш сарымсак, укроп, 4-5 данә кара борыч, канәфер, дәфнә яфрагы (лавр) салына. Аннан соң кыярларны тезәбез.

**Тозлау өчен кирәк:** *1,5 л су, 5 аш кашыгы шикәр комы, 3 аш кашыгы тоз.*

Тозлыкны бер тапкыр кайнатып, кайнар килеш банкаларга агызабыз. Әзер булган банкаларны «сулы мунча»да тотабыз. Аларны тимер капкач белән япканчы, 100 грамм аш серкәсе өстибез.

АТНА ВАКЫЙГАЛАРЫ
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Татар–информ» мәгълүмат агентлыгында әзерләнде.

Генераль директор – Шамил Мөхәммәт улы Садыйков.
Баш редактор – Рәмис Нурмөхәммәт улы Латыйпов.
Шеф–редактор – Алсу Исмәгыйлева.
Җаваплы редактор – Лилия Гаделшина.
Дизайн–верстка – Светлана Щеглова.
Корректор – Раис Габдуллин.

Тел.: (843) 222–09–83 (1304; 1414)
Редакция һәм нәшир адресы:
420066, Казан ш., Декабристлар ур., 2нче йорт.
Эл.адрес: info@tatar–inform.tatar
Реклама хезмәте телефоны: (843) 570–31–07

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсендә Федераль күзәтчелек хезмәтенең (РОСКОМНАДЗОР) Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2014 елның 9 гыйнварында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы: ПИ №ТУ16–01140
Басмага бирү вакыты: 3 июль 2019,
график буенча – 24.00, гамәлдә – 24.00

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» АҖ

Нәшир адресы:
420097, Казан ш., Академия ур., 2
**Басылу урыны:**
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы
«Идел–Пресс» полиграфия–нәшрият комплексы.,
Казан ш., Декабристлар ур., 2
Тираж –48 337 экз.

**Гомуми тираж: 67 099 экз.**

Редакция фикере автор фикере белән туры килмәскә мөмкин. Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
Реклама игъланнарының дөреслеге өчен реклама бирүче җаваплы.

© Язмаларны күчереп бастыру фәкать редакция рөхсәте белән генә башкарылырга тиеш. Газета атна саен чыга. Бәясе ирекле.

*«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла*

16+